КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни ЖОМГА

№ 22
15 декабрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



БҮГЕНГЕ САНДА

2 *Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.* Татар дөньясына сөмсез сыер кебек сөзеп килеп кергән ят, ямьсез гадәтләрдән ничек арынырга?

5 *Кыям МИҢЛЕБАЕВ.* Ике кулына бер эш тә булмагач, кеше ул күрәләтә өшәнә, һәммә нәрсәгә битараф, барчасына гамьсез карарга өйрәнә.

16 *Барлас КАМАЛОВ.* Мең елдан артык тарихы булган әдәбиятка, гаҗәеп биеклекләр яуларга өлгергән театр, җыр-бию, нәфис сүз дөньясына иң җитди карашны дауларга хаклыбыздыр без.

19 *Әбрар КӘРИМУЛЛИН.* Без хәтта хәзерге көннәрдә дә әле үзебезнең милли азатлык өчен көрәш тарихыбызга тиешенчә игътибар бирмибез, бу көрәшнең маяк булган фактлары турында сүз алып барырга да куркабыз.



Изгеләрдән изге китапларга
Фәрештәләр канат тигезгән...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Дөнья яралу белән, Җирдә Аналар хакимлеге урнашкан, диләр. Ләкин тора-бара яшәешнең табигый агышы үзгәргән, бөтен хакимият ирләр кулына күчеп беткән. Һәм шуннан мәхшәр купкан, кискен үзгәрешләр килеп чыккан. Хәлбуки, җәмгыятьтә әле дә хәтәр эверелеш бара... Әгәр дә хатын-кыз заты ир-атка охшарга тырышса, өстәвенә үзенә ирләрдәге иң начар сыйфатларны да сеңдерсә, безнең оныкларны кем табар да, кем багар киләчәктә соң? И Тәңрем, без, адашкан җаннарыңа кайтыр юлны күрсәтсәңче?!

Газинур МОРАТ

МИН ӘЙТТЕМ

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Әхлаксыз йорттан оят качар

Бу гасыр — безнең буын өчен газап-хәсрәтләрне җаныбыз белән дә, тәнебез белән дә татып яшәгән каршылыклы, фаҗигале гасыр булды. Эшләгән эшебез — бәһасез, тапкан балаларыбыз — шәфкатьсез. Әйтик, кемдер үзен тудырган әнисен, авызына кайнар су коеп, ерткычларча җәзалап үтерә һәм җансыз гәүдәсен тураклап этләргә бирә. Унике яшьлек фахишә үз «һөнәре»ннән тәм табып яши, ләззәтләнеп сөйли ала. Җиде җан тудырган хатын, балаларын суеп, төрмәдә утыруны кулай күрә. Кечкенә чакта песи асып, көчекләрне суга батырып, газаплы үлемнәрен игътибар белән күзәткән берәү — үсеп җиткәч шул эшен дәрәҗә итеп телгә ала... Йә Алла, ата-улны, ана кызны белмәс кыямәт көне түгелдер ләбаса инде бүгенге яшәешебез? Баш тулы сорау, бәргәләнү, чарасызлык.

Нишләргә? Дөньяны ничек җайга салырга? Татар дөньясына сөмсез сыер кебек сөзеп килеп кергән ят, ямьсез гадәтләрдән ничек арынырга?.. Соңгы вакытта әнә шундый ачынулы уйлар белән яшәүче хатын-кызларыбыз күбәйгәннән-күбәйде. Әмма бу ил белән килгән шәфкатьсезлектән, тәрбиясезлектән чыгу юлын тегендә — ун, монда утыз хатын-кыз җыелып сөйләшеп кенә хәл итеп булмый. Монда бөтен республика хатын-кызлары күтәрелеп, олы сөйләшү алып барырга, фикерле, акыллы, тәҗрибәле хатын-кызларыбызны, ил Аналарын җыеп киңәшләшергә, уйланырга, кешелексезлек сазлыгыннан чыгу юлларын эзләргә кирәк. Ул сөйләшү дәүләт дәрәҗәсендә булырга тиеш.

Тагын бер атнадан — нәкъ шундый сөйләшү — Татарстан хатын-кызлары съезды була. Бигрәк тә нинди сорау, беренче итеп нинди мәсьәлә күтәрелер анда?

Бүгенге көндә бик күп хатын-кызларның эшсез калуы яки яшь аналарның балага узгач ук эш урыннарында кадерсез кешегә әйләнүеме; тел белмәү аркасында әби-бабай белән онык арасына упкын булып яткан буыннар өзеклеге яки ата-ана белән бала арасындагы кискен каршылыкмы; китек, ким гаилә яки ятим һәм ташлап калдырылган сабый язмышымы; караучысыз калган карт әти-әниләребез яки солдат улларыбыз фаҗигасеме; әллә инде илдә таралган җенси авыруларның коточкыч зур саннар белән билгеләнүеме? Хикмәт мәсьәләнең кайсы беренче булып куелуында түгел, хикмәт — съездның хатын-кыз тормышында киләчәктә уңай якка үзгәреш ясый алырлык карарлар чыгаруында, минемчә.

Бүгенге көндә хатын-кызның иң күп тупланып эшли торган урыны түбәндәгеләр: гомуми туклану хезмәте — 88,9; халык мәгарифе — 86,2; сәламәтлек саклау учаклары 83,5 процент. Мин шуларның бары берсенә — мәктәп, укыту-тәрбия мәсьәләсенә күз салып үтмәкче булам.

Татарстан мәгарифе системасында бүгенге көндә 128,2 мең кеше эшли. Шуларның 106,4 меңе хатын-кыз. Араларында бүген утырып китап яза алырлык язучылар, сәхнә кешесе булып китәрлек җырчылар, музыкантлар, җитәкчелек сәләтенә ия булган талантлы шәхесләр күп. Шул күпләр арасында татар теле һәм әдәбияты укытучыларын аеруча зур хөрмәт белән искә алыр идем. Йә Алла, нинди генә михнәтләр күрмәде алар татар теле каһәрләнгән, көчләп укытыла башлаган елларда.

Музыка, хезмәт, физкультура кебек әһәмияте аз дип исәпләнгән сәгатьләрдән татар балаларын аерып алып, ана теле дәресләре үткәрергә кирәк. Тик җырга, кул эшенә, спортка сәләтле татар баласы, иптәшләреннән аерылып, «поршивый» дәрескә кермәс өчен җан тартыша. Татар булып туганы өчен үкенә. Бу хурлыкны классташлары алдында фаш иткәне өчен татар теле укытучысын шәхси дошманы итеп саный. Кыскасы, ул елларда әнә шундый «педагогик юл» белән бала күңелендә: татар теленә, татар милләтенә, татар теле укытучысына нәфрәт тәрбияләнде.

Моннан ун еллар чамасы элек Балык Бистәсе районының бер урыс мәктәбендә булырга туры килгән иде. Гадәтемчә, беренче эшем итеп, татар теле укытучысын эзләп таптым. Шул вакытта бу яклаучысыз җан иясенең үзәк-бәгырьләре өзелеп елавы әле дә күз алдында. «...Исе һаман бетми... Татар теле һәм әдәбияты өчен бүлмә сорап җаннарына тигәч, әнә бәдрәф, кирәк икән, ремонтла да кер, диделәр...»

И-и, бу татар кешесенең берсен-берсе якламавы һәм сакламавы. Шул вакытта әлеге мәктәптә ничәмә-ничә татар хатыны, татар ире эшләгән бит инде. Хезмәттәшләрен шул кадәр мәсхәрәләргә юл кую, бу кадәр гамьсезлек һәм бу кадәр битарафлык башка бер милләттә бар микән?

Зур агачны көчле җилләр дә сирәк ега. Күбесенчә вак корт ашап, эчтән кимереп черетә мәһабәт агачны. Без дә күп җирдә үз тәнебезгә үзебез корт булып керәбез шикелле.

Кыскасы, ана телебезгә, милләтебезгә булган бүгенге мөнәсәбәт корбаннарсыз гына килмәде. Ул юлда мораль яктан изелүчеләр, бөтен саулыгын югалтучылар, хәтта җаннарын фида кылучылар булды. Алар: татар теле мөгаллимнәре, башлангыч класс укытучылары, китапханәчеләр, татар җанлы кешеләр иде. Бу фидакарьләрнең җан газабы янында бил тиңентен суга кереп, сазлыктан торф чыгару, шахта базларына төшеп, күмер чабу бәлки җиңелрәк тә булыр иде. (Алары да татар хатын-кызы өчен ят эш түгел). Әмма шуны әйтәсе килә, ул елларда татар теле һәм әдәбияты укыткан һәм башка татар җанлы мөгаллимнәрнең туган телне саклап калу өчен алып барган көрәшен — Ватан сугышында илне саклау өчен яуга кергән каһарманнарга тиңләр идем!

Мисаллар күп, нәтиҗә бер. Киләчәкнең сәламәт акыллы баласын үстерү өчен бүгенге укытучының зур абруйлы булуы сорала. Укучы үзенең мөгаллимәсен яки мөгаллимен үз буе җитмәслек биеклектә күргәндә генә, аңа сокланып, гыйлеме, холык-фигыле белән илһамланып укыганда гына — нәтиҗә канәгатьләнерлек була.

Республикабызның хөрмәтле хакимият башлыклары, укытучының абруен күтәрү — иң беренче чиратта Сездән тора. «Волга» ачкычлары димим, эшләгән хезмәт хакларын гына вакытында түләгез Сез аларның. Юк чагында да җаен табыгыз. Укытучы халкы гамьсез була алмый. Аш атканга таш ыргытмаслар.

Элек авылларда хатын-кызлар оешмасы (женсоветлар) бар иде. Бу эшне, гадәттә, укытучылар җитәкләде. Ялкынландырып, дәртләтеп җибәрәсе иде шуларны. Иманыбызга кайту юлында күп файда китерер иде алар. Бигрәк тә балаларның әти-әниләрен санлап, олылап яшәвенә ирешүләрен, аларны башлы-күзле итүдә дә борынгы матур сыйфатларыбызга күз салуларын теләр идем.



Бүгенге көннең бары тик хатын-кыз күзе генә күрә, хатын-кыз йөрәге генә ишетә алган фаҗигале яклары күбәйде. Башка чыккан балалар кебек, һәркайсы үз көнен үзе күреп яшәүче оешмаларны бер үзәккә берләштереп, корт анасы кебек, эшче кортларына илне савыктыру гыйлемен өйрәтеп тора алырлык, дәүләт дәрәҗәсенә куелган хатын-кызлар комитеты төзелү — эшнең башы булыр иде.

Исемләп эндәшә башлагач, Сезгә дә җиткерер фикерем бар икән, Камил Шамилевич! Сүзем һаман да шул татар теле укытучылары хакында. Әмма бүгенгеләре әле яңа гына тормышка аяк баскан педколледж, педучилищеларда туган телебезне укыту өчен махсус әзерләнгән япь-яшь кыз балалар турында. Бик күбесе үзе эшләгән мәктәптән ерак урнашкан, Казан шәһәренең төрле төбәкләрендәге эшче тулай торакларында яши аларның. Шунда ук яшәүче исеректән, кайчан тибеп ишегемне ватар да үземнә кереп ботарлар, дип куркып көн итә. Заводлар үз эшчеләренә аерым торак йортлар төзегән кебек, укытучыларның да үзләре өчен дип салынган тулай торaклары булсын иде. Методик үзәк, остахана вазифасын үтәүче күркәм бер урын да булыр иде ул.

Соңгы елларда чит илләр белән аралашу безнең дә күзне ачты. «Балам, син — татар, дип йокысыннан уятам. Балам, син мөселман, белгәнеңне укы, дип урынына яткырам», дип сөйли ерак илдән килгән бер ханым. Инсафлы татар хатынының, сабыен ак җәймә япкан урын-җиргә салып, әкрен генә колагына пышылдаганы күз алдына килә: «Балам, син — та-тар!..» Тәрбияме бу? Сокланырлык тәрбия. Ничәмә ничә буыны җидә ят арасында туган, тәрбияләнгән, ә телне, динне онытмаганнар.

(Ахыры 6 нчы биттә).

Аксакал композитор Президент белән очрашты

Бу көннәрдә республикабыз җәмәгатьчелеге мәшһүр композитор Әнвәр Бакировка 75 яшь тулуны билгеләп үтә. Республиканың мәдәни тормышындагы шушы истәлекле вакыйга уңаеннан композиторны Президент М.Шәймиев кабул итте.

Эчкерсез, җылы әңгәмә вакытында сүз хәзерге чорда әдәбият һәм сәнгатьнең торышы турында барды. Үз иҗатына югары бәя биргән өчен, акыл хезмәте вәкилләренә конкрет ярдәм күрсәткән өчен композитор Президентка рәхмәт әйтте.

М.Шәймиев халыкның рухи-әхлакый, эстетик тормышында иҗат интеллигенциясенең мөһим ролен күрсәтеп үтте. Шул ук вакытта, дәүләтебез яңарыш чоры кичергәндә, иң яхшы милли традицияләребез, иҗат әһелләре хезмәтенең әһәмияте арта бара, диде ул. Ә бу, нәтиҗәле эшчәнлек өчен кирәкле шартлар тудыру дәүләт органнарының иң беренчел бурычларыннан берсе булып тора, дигән сүз. Шушы максаттан чыгып, Татарстан Республикасы парламентында 1996 елга әле генә расланган дәүләт бюджетында шактый средстволар каралды. Республика Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә булышлык фонды да бу юнәлештә зур тырышлык куя.

М.Шәймиев Ә.Бакировка озак еллар иҗат эшчәнлеге, сәламәтлек һәм бәхет теләде.

Очрашуда Премьер-министр урынбасары И.Хәйруллин, мәдәният министры М.Таишев катнашты.

Китап йортында бәйрәм

Татарстан Фәннәр академиясе, Мәдәният министрлыгы, Милли китапханә Татарстан Республикасының Милли китапханәсенә 130 ел тулу уңаеннан «Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре» дип исемләнгән конференция үткәрә. Аның барышында «Гасырлар авазы», «Могҗизалы борынгы шәһәр» дигән китап күргәзмәләре эшли. Конференциянең пленар утырышы, китап белеме, китапханә һәм музей белеме секцияләре эше зур җанлылык белән үтте.

● Гәзитебезнең беренче битендә Рөстәм Мөхәммәтҗанов фоторәсеме.

Җидегән

5 6 7 1 2 3 4

вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Өстәлдә ак кәгазь

Язучы Габдулла ШӘРӘФИ

— Каләмегездән ниләр тама? — дигән соравыбызга болай җавап бирде:

— «Гөмер арбасы» дигән повестьнең каһарманы күпмедер вакытлар үткәч, олы яшька, гомеренең яртысына җиткәч әйтә:

— Гомеремнең арбасына артымның яртысына гына утырып, аягымны салындырып бардым, ди.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Республикасы Президенты фәрманы белән **Татарстан Республикасының Мактау грамотасы** белән

татар музыка сәнгате өлкәсендәге зур казанышлары өчен композитор **Әнвәр Закир улы БАКИРОВ**,

татар театр сәнгатен үстерүдәге казанышлары өчен һәм 80 яше тулу уңаеннан Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты **Һидиятулла Айниатулла улы СОЛТАНОВ** бүләкләнде,

татар музыка сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен Чаллыдагы «Салават» җыр театры солисты һәм директоры **Салават Зәки улы ФӘТХЕТДИНОВ**ка **«Татарстан Республикасының халык артисты»** дигән мактаулы исем,

Чаллы Татар дәүләт яшьләр театры артисты **Гөлүсә Гомәр кызы ЯМАЛИЕВА**га **«Татарстан Республикасының атказанган артисткасы»** дигән мактаулы исем,

Бөтенрусия сукырлар җәмгыятенең Казан «Электроконтакт» укыту-производство предприятиесенең мәдәният йорты баянчылар ансамбле җитәкчесе **Евгений Дмитриевич ФРОЛОВ**ка **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Русия Федерациясе Президенты фәрманы белән Русия Зур академия театры оркестры дирижеры **Фуат Шакир улы МАНСУРОВ**ка **«Русия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Тотошка дигән тере биштәр

Казан базарларының берсендә саклау камерасы хезмәткәре киштәләргә тезеп куелган бер биштәрнең кинәт селкенеп куюын сизеп ала. Чакыру буенча килеп җиткән милиционерлар биштәр эченнән кечкенә генә буйлы... яшүсмерне табып алалар: Зегыйфьлеге аркасында үсмичә калган Тотошка кушаматлы 16 яшьлек малай каракларның үтә дә хәйләкәр бер эшендә ярдәм итәргә тиеш булган икән. Кичен караклар саклау камерасына дүрт зур биштәр тапшыралар, шуларның өченсенә кирәксез чүпрәк-чапрак тутырылган. Төнлә Тотошка аларны бушатып, биштәрләргә кыйммәтле күнкән тегелгән әйберләр тутырырга тиеш була. (Саклау камерасында шундый кыйммәтле товарлар барлыгын каракларга үз кешеләре җиткергән). Ә иkенче көнне Тотошканы шул ук кешеләр саклау камерасыннан алырга тиеш булалар. Милиция аларны да эләктерә.

«Яшь йолдыз-96» чакыра

Идел буе республикалары һәм шәһәрләренең «Яшь йолдыз-96» популяр музыка һәм заманча биюләр фестивале быел үзенең биш еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнә.

Биш ел элек, фестивальне оештыруны җибәргәндә, аның директоры Валерий Колоколов болай ди: «Без талантларыбызны күрсәтү өчен Мәскәүгә дә, башка җиргә дә барырга теләмибез. Киресенчә, алар үзләре безгә килсеннәр».

Аның бу сүзләре фестивальнең икенче елында ук тормышка аша башлый. Республиканың талантлы иҗат коллективларын, егет-кызларын ачыклау, аларга эшләү өчен шартлар тудыру, төрле милләттәге җырчы һәм биюче яшьләрне мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә берләштерү максатында оештырылып җибәрелгән фестивальнең икенче елында ук Казанга Түбән Новгородтан, Ярославль өлкәсеннән, Украинадан сәнгать коллективлары килә.

— Быел, юбилей елы буларак, фестивальнең географиясен тагын да киңәйтергә, масштаблырак итәргә ниятләдек, — дип сөйли Валерий Колоколов. — Сентябрь аенда ук Ульяновски, Волгоград, Әстерхан шәһәрләрендә сайлап алу турлары үткәрелде. Бу төбәкләрдән фестивальгә 16 коллектив һәм, әйтергә кирәк, бик көчле коллективлар килә. Уфа, Тольятти, Түбән Новгород шәһәрләреннән фестивальдә катнашучы тәркемнәр дә тәгаенләнде инде. 16-17 декабрьдә шундый ук эш республика күләмендә алып барылачак.

«Яшь йолдыз-96» фестивале кече (5 яшьтән 13кә кадәр), урта (14 яшьтән 17гә кадәр) һәм өлкән (18 яшьтән 23кә кадәр) яшь категорияләре буенча уздырыла. Тик шунысы күңелне борчый: фестивальдә, инде бишенче елын үткәрелсә дә, республикабызның татарлар күпләп яши торган районнарына үтеп керә алмаган.

— Биредә күпмедер дәрәҗәдә «Татарстан» телевидениесенең дә гаебе бар, — ди В.Колоколов. — Фестивальнең бер генә тапкыр булса да телевидение аша күрсәтелүенә, һич югы аның турында мәгълүмат бирелүенә ирешә алганыбыз юк. Яңа елның февралендә узачак фестивальгә республикабызның барлык төбәкләрендә яшәүче яшь талантларны чакырабыз. Алар мәгълүмат алырга теләсәләр, 32-42-67 телефоны белән шалтырата алалар.

«Чишмә» челтәрәвеннән тальян моңы ишетелә

Ульяновскидагы «Волга» телерадиокомпаниясенең «Чишмә» тапшыруы өлкә тарихында беренче тапкыр «Уйна, Сембер гармуны!» дигән телевизион фестиваль уздырды.

Анда өлкәнең барлык районнарыннан килгән гармунчылар белән бергә Татарстанның Апас, Буа, Чүпрәле, Тәтеш районы, Чувашстан һәм Башкортстан республикаларыннан, Самара өлкәсенең Елховка районыннан да 70тән артык гармунчы катнашты.

Шәһәрнең үзәк концерт залында узган әлеге театральләштерелгән тамашада биш яшьлек сабыйлардан алып 80 яшьлек бабайларга кадәр чыгыш ясады. Фестивальдә катнашучыларга Чынлы районы хакимияте әзерләгән кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Ә иң кыйммәтлесе һәм иң кызыклысы — сәләтле балалар мәктәбендә укучы Ленар Мәсәлимовка бирелде. Аңа өр-яңа тальян гармун, чигүле түбәтәй һәм акчалата бүләк тапшырылды. «Чишмә» тапшыруы мөхәррире Рамис Сафинның әйтүенә караганда, алдагы елда редакция «Бөет мөнәҗәтләр» кичәсе уздырырга ниятли.

Рәмилә САФИНА.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Кремльдә Төркия Республикасының Русия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Бильгин Унанны кабул итте.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында күренекле композитор Әнвәр Бакировның иҗат кичәсе булып үтте.

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Зөфәр Бохараев Татарстан Республикасының Кинематография дәүләт комитеты рәисе итеп билгеләнде.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык артисты Һидият Солтановка 80 яшь, иҗат эшчәнлегенә 60 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде.

Киләсе елда Мәскәү дәүләт университеты нәшриятында татар телендә беренче басма китап — Сәгыйть Хәлфинның «Татар теле әлифбасы» исемле дәреслеге 217 елдан соң кабат дөнья күрәчәк.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Татарстанның атказанган артисты Җәвһирә Сәлахованың бенефисы булып үтте.

Казанның Борнай мәчетендә Татарстан имамнары шурасының икенче утырышы булды.

Дәүләт Советында

Роберт МИҢНУЛЛИН

Телгә дигән акча кая киткән

(Татарстан Президентының 1996 елга бюджет юлламасын тикшерүгә багышланган сессиядә ясалган чыгыш)

Без бу арада киләсе ел өчен республика бюджеты турында күп сөйләштек Әйтәсе сүзләр әйтелеп тә бетте шикелле Аңлаган кешегә аңларлык булды Менә мин дә тагын нинди матур сүзләр әйтергә икән дип баш ваттым Үзебезнең мәдәниятебезне яклап. матбугатны, радио-телевидениене. киноны. фәнне. балаларыбызны яклап нинди генә тылсымлы сүзләр әйтергә? Президентыбызны. Премьер-министрны. финанс министрын йомшартырлык. күңелләрен нечкәртерлек. аларны ышандырырлык нинди сүзләр табарга да аларны ничек кенә үзебезнең мәдәният ягына аударырга? Ләкин күпме генә эзләсәм дә. андый сүзләрне таба алмадым ·Барысы да әйтелеп беткән бугай. .

Без соңгы вакытта «Мәдәни һәм тарихи хәзинәләрне саклау һәм алардан файдалану турында»гы Законны беренче укуда кабул иттек. «Мәдәният турында»гы Закон проектын әзерләп бетердек. «Республикада китап бастыру эшенең торышы» турында парламент тыңлаулары уздырдык Сүзебез һаман да бер үк мәдәниятебезнең язмышы куркыныч астында! Депутатлар сөйли тора, җитәкчеләр тыңлый тора. Шуның белән вәссәлам! Киләсе ел бюджеты белән дә шул ук хәл килеп чыгар шикелле Менә ничә атна инде без ул бюджет проектын өйрәнәбез тикшерәбез, тәкъдимнәр кертәбез Финанс министры урынбасары А Шишкин көннәр буе безнең белән Депутатлар сөйли. сорау бирә тәнкыйть итә Алексей Геннадьевич минем кебек тыныч кына башын аска иеп утыра, кыска гына җаваплар бирә. Ярар, карарбыз ди дә тыныч кына кайтып китә Министр беләнниләр сөйләшәләрдер, билгесез Әмма шунысы хак. берни дә үзгәрми, барысы да шул килеш кала.

Шуңа да карамастан быелгы сөйләшүләрнең кайбер нәтиҗәләре булмый калмас шикелле Бюджет буенча Закон проектының яңа вариантында республика бюджетыннан 10 млрд сум өстәлгән Ләкин бу мәсьәләне хәл итү түгел Радио-телевидениегә дә бераз гына арттырылган Бусы да бик аз Шулай да Татарстан телевидениесе киләсе елда тырышып-тырмашып булса да үзенең тапшыруларын тагын бер сәгатькә арттырып бөтенесе алты сәгатькә җиткерер дигән өмет бар Чагыштырыр өчен шунысын да әйтим Удмуртия телевидениесе бүгенге көндә үзенең тапшыруларын тәүлегенә ундүрт сәгать алып бара Аларга да акча күктән төшмидер югыйсә Бюджет комиссиясе рәисе Г Кобылев «депутатларның замечаниеләре учтены» диде диюен әмма Матбугат министрлыгына кинога бер тиен дә арттырылмаган һәм бу һич тә аңлашылмый Безнең хөрмәтле журналистларыбыз да бу хәлне аңламаслар һәм аңларга да теләмәсләр дип уйлыйм



Туфан Миңнуллин дөрес әйтә. аракы сату эше бездә шәп куелган. Татарстан аракыга коена Исерек. эчкечә Татарстан Китапка гына акча юк. Безнең комиссия матбугатка һәм китап бастыруга 36 млрд. 613 млн сум сораган иде Кабатлап әйтәм. бер тиен дә арттырмаганнар. Ә гәзит-журналларыбыз кызганыч хәлдә Кыяфәтләренә карарлык түгел, укырлык. танырлык түгел Берничә ай инде журналларыбыз чыга алмыйча ята. Республикада кәгазь юк. Шул ук вакытта «Крис», «Ва-банк» кебек унарлаган реклама гәзитләре 250шәр мең тираж белән яхшы сыйфатта чыга һәм халыкка бушлай таратыла. Безгә шулардан өйрәнергә кирәк түгелме? Акчаны алар кайдан таба икән? Шушы сорауга җавап бирерлек берәр кеше бармы бу залда?

Китап турында да бу арада күп сөйләштек Тагын кабатлыйм Башкортстан китап нәшриятына киләсе ел өчен 18 млрд сум бирелгән. Бездә исә ике дәүләт нәшриятына — 6 млрд сум Бу — адәм көлкесе Бу — тарихыбыздан. мәдәниятебездән, язучыларыбыздан көлү. аларны санга сукмау. Бюджетны без кабул иткән булабыз Ләкин Финанс министрлыгы анысын да яшереп калдыра Мәсәлән. Татарстан китап нәшрияты быелгы акчаның 43 процентын гына алды Шул ук сәбәп белән «Мәгариф» нәшрияты тиешле дәреслекләрнең 40 процентын гына чыгара алды Гонорарларны әйтергә дә оят. Үземнән бер генә мисал китерәм Телевидениедән мин «Ихлас» исемле тапшырулар циклы алып барам Берәр сәгатьлек зур тапшырулар Ике-өч көн төшерәсең, берничә көн монтажлыйсың, сценариен язасың, вакытыңны, энергияңне сарыф итәсең Шуңа күпме гонорар ала дип уйлыйсыз? Соңгы тапшыру өчен кулга 39 мең сум тоттырдылар Гәзит-журналларда, нәшриятларда да шул ук хәл

Без телләр турында Закон һәм шул Законны тормышка ашыру буенча Дәүләт программасы кабул иттек Быелгы бюджетта аңа 4 млрд сум каралган иде Киләсе ел өчен 5 млрд сумнан чак кына артыграк Инфляцияне исәпкә алсак быелгыдан да кимрәк булып чыга бит! Ул гына да түгел, әлеге 4 миллиардның 1 миллиарды гына тотылган булып чыкты Татар телен үзең белмәгәч башкалар да өйрәнмәсен дигән сүзме инде бу? Шулай да министр әфәндедән сорыйсым килә безнең телгә мәдәниятә, матбугатка. китапка дигән акчаларны кая куеп бетердегез? Кемгә бирдегез безнең хәләл акчаларыбызны? Бу – үз халкыңа каршы эшләү гомумән республикада телләр турындагы Законның үтәлешенә аяк чалу дип исәпләнергә тиеш Димәк татар теле һаман да мескен кухня теле урам теле булып калачак Мин инде суверен республика булгач «мөстәкыйльлек. дәүләт телләре» дип бик еш мактанышкач, үзебезнең мөстәкыйльлегебезнең бишьеллыгын бик шәп итеп уздыргач мәгарифкә, мәдәнияткә. матбугатка балаларга һәм яшьләргә игътибар бермә-бер артыр, бюджеттан акча күбрәк бүленер дип көткән идем Әмма болар барысы да гадәттәге шапырынулар гына булып чыкты

Әлбәттә, авыл хуҗалыгы да, промышленность та, транспорт та, башкалар да бик мөһим Аны гына аңламаска без диваналар түгел. Ләкин шунысына иманым камил, без кешенең рухи культурасын икенче планга куеп, мәдәниятебезне, әдәбиятыбызны. мәгарифебезне. фәнебезне кимсетеп, халкыбызның тормышын бервакытта да югары дәрәҗәгә күтәрә алмаячакбыз. Рухи ачлык безне бик күп бәлаләргә китерер. Дөрес, республикабызда әлегә иминлек, тынычлык хөкем сөрә. Ләкин ул тыштан гына шулай күренергә мөмкин. Халык барысын да белә, аңлый. барысын да күреп тора «Барысы да ал да гөл, барысы да әйбәт» дип үзебезне үзебез алдамыйк.

Сүземне кечкенә бер притча белән тәмамламакчы булам 60 нчы елларда Башкортстан өлкә комитетына яңа идеология секретаре билгеләнә Беренче көнне эшкә килә бу Килүенә кабул итү бүлмәсендә башкортның Буранголов фамилияле бер өлкән язучысы утыра. «Иптәш секретарь, сезгә бер генә сүзем бар иде», — ди ул Секретарь аны бүлмәсенә дәшә «Әйдә. агай, әйдә!» Керәләр Язучы сүз башлый «Менә иптәш секретарь, сез акыллы кеше инде сез беләсез инде. безнең язучы халкы. кәнишне, погода ясый алмый инде но погоданы испортить может Менә шул иде минем сүзем», — ди дә чыгып китә Мин моны ни өчен сөйләдем соң? Әлбәттә инде, безнең республикада да иҗат кешеләре — язучылар журналистлар, галимнәр, сәнгать кешеләре погода ясый да алмыйлардыр Әмма алар погоданы бозарга чыннан да бик мөмкиннәр Ул чиккә үк җиткермәсәк иде без аларны

Мин ни телим халкыма?

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлеге 19 декабрьдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның иҗат кичәсен үткәрә. Тамашачыларны 18 сәгатьтә кичәгә дәшкән афишаларда шагыйрәнең канатлы сүзләре бирелгән: «Мин үземә нәрсә телим, — шуны телим халкыма».

Кичәдә танылган сәнгать әһелләре — Айрат Арслан, Усман Әлмиев, Лариса Маслова, Хәмдүнә Тимергалиева, Клара Хәйретдинова, Мөнир Якупов, Гөлзада, Люция Хәсәнова, Мөнирә Хәбибуллина, Рәшит Сабиров, Искәндәр Биктаһиров, Зөһрә Шакирҗан, Илдус Сафин, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «Рух» скрипкачылар ансамбле катнаша.

Күлдән — диңгезгә

Дәүләт Советының булып үткән соңгы сессиясендә шәхси гаризалары нигезендә ике депутат — Мамадыш һәм Әлки районнарының элеккеге хакимият башлыклары Рафаэль Әхмәтов һәм Хәлим Сафин вакытыннан алда үз вәкаләтләреннән азат ителде. Бу җитәкчеләрнең беренчесе хакында матбугатта сүз күп булды. Аны эшеннән шәхси тыйнаксызлыгы, районда әхлакый вәзгыятьнең начараюы (хакимият башлыкларын алыштыру турындагы указларда әлеге сүзләр, ялгышмасам, беренче тапкыр кулланылды) өчен алдылар һәм республиканың дәүләт нәсел берләшмәсе җитәкчесе итеп куйдылар. Татарча әйтсәк, чуртанны күлдән алып диңгезгә җибәрү була түгелме соң бу? Аның шәхси тыйнаксызлыгын хәзер республика күләмендәге берләшмә дәрәҗәсендә тоярга тиеш булачаклармы?

Гомумән. хакимият башлыклары тирәсендә аңлаешсыз хәлләр бара шикелле. Быел язын булган сайлауларда Менделеев районындагы 45 нче административ-территориаль округтан депутат булып район Советы рәисе Сәлим Хәбибуллин сайланды. Гадәттә, бу төр округтан сайланган депутат хакимият башлыгы итеп билгеләнә иде. Тик Менделеев районында бүгенге көндә хакимият башлыгы булып әлеге депутат түгел, башка кеше эшли Ә менә Спас районында шундый ук сайлау округыннан депутат булган К.Нугаев икенче көнне үк район хакимияте башлыгы итеп билгеләнде. Менә шундый хәлләр.

Наил ФӘЙЗЕТДИН.

«Иркәмә» дигән җырны сагынам

«Мәдәни җомга»да эшләүче иптәшләр! Минем сезгә бик зур бер үтенечем бар. Без яшь чакларда, бу 1953-54 нче еллар булгандыр (миңа ул чакта 24 яшьләр чамасы иде), радиодан «Иркәмә» дигән бер матур җыр ишетелә иде. Бик тә матур, моңлы бер җыр иде ул. Мин аның көен дә һаман хәтеремдә саклыйм. Сүзләре дә хәтердә.

Сөям дигән ихлас сүзең белән
Ашкындырдың мине бүген дә.
Татлы сүзләреңне түгел, үзеңне дә
Саклыйм, иркәм, күңелем түрендә.

Шушы җырны минем күптән инде беркайда да ишеткәнем юк. Бу җырны безнең яшь җырчыларыбыз белә микән? Ул онытылмады микән? Бу хакта кызыксынучы бар микән?

Мин үзем элекке Дөбьяз районы Дөбьяз авылында туып үстем Казанда яшим. «Иркәмә» җырының очына чыга алсагыз, бик тә, бик тә рәхмәтле булыр идем Ул, минемчә, күпләрне яшьлегенә алып кайтыр иде.

Рәшидә ГЫЙЛЬМАНОВА.

Руслан МӨХӘММӘТҖАНОВ

Каты авырудан соң 11 декабрьдә Татарстан китап нәшрияты директоры урынбасары, язучы һәм журналист Руслан Сөләйман улы Мөхәммәтҗанов вафат булды

Руслан Мөхәммәтҗанов 1944 елның 6 июнендә Чирмешән районының Чумачка авылында туган Хәрби хезмәттән кайткач, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлап, республика газета-журналларында, телевидение студиясендә эшләде Соңгы вакытта ул Татарстан китап нәшриятында директорның китап сәүдәсе буенча урынбасары хезмәтендә булды

Журналистлык эшчәнлеге белән бергәттән, Р Мөхәммәтҗанов язучы буларак та киң танылды Аның «Бүре сагышы» исемле китабын укучылар яратып кабул иттеләр Күптән түгел каләмдәшебезнең «Әнием төсе» исемле китабы дөнья күрде

Руслан Мөхәммәтҗанов тынгысыз җанлы, саф күңелле һәм шат рухлы яхшы иптәш иде Без аның гаиләсе, туганнары һәм якыннарының олы кайгысын ихлас уртаклашабыз Хезмәттәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләребездә озак сакланыр

Татарстан китап нәшрияты коллективы.

Хәтер кайтавазы

Кыям МИҢЛЕБАЕВ

Авылымны уйлап уйга калсам...

(Нәсер)

(Дәвамы. Башы 21 нче санда).

Халыкның хәле никадәрле мөшкелрәк булса, түрәләрнең әдәп-инсаф дигән нәрсәне бөтенләй онытуларын, ни Алладан, ни бәндәдән курыкмаенча эш итүләрен, оятсызланып китүләрен бер бүген генә күрүем түгел инде. Түрәләрнең «үзгәртеп кору» дәверендә халыкны бөлгенлеккә дучар итеп, үзләренең чамадан тыш азынуларына гаҗәпләнмәвем дә, ихтимал, шуннан калгандыр. Чөнки «уфалла»ны төпкә җигелеп тартып кайтканда, каршыбызга ике-өч йөк бодай төягән колхоз җитәкчеләре очрагач, аптырап калганым әле хәзер дә исемдә. Хәер, унике яшьлек малай гына түгел, тормышның ачысын-төчесен татырга өлгергән юлдашларыбыз, җиде-сигез авыл хатыны да телсез калды бугай. Капчыклар өстенә менеп кунаклаган колхоз рәисе, өтәчләнүен онытып, тавыкларга гына түгел, минем ише бер чебигә дә сәлам бирергә әзер иде. Аның именеп китүе, чыраеның каралып-янып чыгуы әле дә күз алдымда. Карап торсаң, чит-ят җирдә авылдашларыңны очраткач, сөенергә генә кирәк иде кебек тә бит, сөенмәде шул рәисебез, бер дә сөенмәде...

Ульяннан алып кайткан тозның беркадәресен өйдә калдырып, күбрәк өлешен янә «уфалла»га салдык та, авылдашларыбыз белән бергә-бергә чуваш якларына сәфәр чыктык. Ул тарафларда бәрәңге күп икән, дигән хәбәр безнең авылга да килеп җиткән иде. Урман арасыннан көйлы юл ярып барган мәлдә нинди газаплар кичерүебезне үзе «уфалла»ны татымаган кеше, ай-һай, аңлар микән? Һәрхәлдә, бездән соңгы буыннарга ул газапларны Ходай күрсәтмәсен. Андыйларын да, башкаларын да!

Ата-ананың кулайрагын сайлап булмаган кебек, үзең өчен милләтне-халыкны да сайлый алмыйсың. Мәгәр мин үз халкымның мәрхәмәтле-шәфкатьле булуын кече яшьтән, гомерем буе, адым саен татый килдем.

Чувашстандагы Татар Сыгыты авылына барып кергәч, дүрт куллап каршы алдылар. Гомерләрен эшләп уздырган апалар, — хәзер алар һәммәсе дә гүр ияләредер инде, гөнаһсыз җаннары оҗмахта булсын! — үзебезне зарыгып көтеп алган кунаклардай күреп, кадерләп-хөрмәтләп өйләренә алып керделәр, казан асып, бәрәңге пешерделәр, самавыр куеп җибәрделәр, табын хәстәрләделәр.

Юл тузаныннан арынгач, битне-кулны юып, табындагы иң кадерле, ярмаланып киткән бәрәңге белән сыйлангач, туйганчы чәйләр эчкәч, алып килгән тозыбыз урынына бәрәңге төягәч, кайтыр юлга кузгалдык. Гәрчә «олауларыбыз» икеләтә-өчләтә авырайган булса да, без аны-моны сизмәдек: хәтта әле урман комында да тәгәрмәчләр батмагандай, «уфалла»лар акылга утыргандай, безгә җиңеллек китерергә тырышкандай тоелды...

Хәлле яши бүген авылым. Фарук абый белән Гөлсем җиңги генә чамасыз картаеп өлгергәннәр — җитмешнең өстенә басу белән ягадагы уллары-кызларының кайтып булышканнарын көтеп яшәр хәлгә төшкәннәр. Бөек Ватан сугышыннан исән-имин туган йортына кайткан чакларында ут уйнаткан, көчен кая куярга белмичә, нинди һөнәр белән мавыгып китәргә аптыраган абзыкаем бүген хәтәр өшәнгән. Ярты гасырдан артык сыер сауган, йортны алып барган, бала-чагасын тәрбия кылган Гөлсем җиңги инде килеп сыердан ваз кичәргә мәҗбүр булган.

Хәер, Мидхәт энекәшләрнең дә бала-чага ишле иде. Әлеге көндә Әсгатьләре генә, читкә китәргәме, авылда төпләнеп калыргамы, дип аптыраганнан гына папирос көйрәтә. Үзен кая гына чакырмыйлар, кулы алтын икән. Ульянда яшәүче кызлары Фәһимә атна-ун көн элегрәк өйне юып чыгарган да, яңадан кайтып, әнисенә булышу йөзеннән керләр юып-өтәләгән икән.

Иртә таңнан килен үзебезгә самавыр көйләп җибәрде. Мидхәт белән икәүләшеп чәй эчеп утырабыз. Шулчак түр өйдәге ишек ачылып китә дә мөлаем йөзле Фәһимә килеп чыга. Аның:

— Нихәл, өбзәй! — дигән сүзләре колагыма онытыла язган моңлы бер көй булып ишетелә. Элек туган-тумача әтиемә нәкъ шулай эндәшеп тә, үземә әле берәүнең дә моңарчы болай диеп әйткәне юк иде. Йа Хода, күңелгә шундый да якын, ягымлы сүзне үз колагым белән ишетергә язган икән ләбаса!

Шау-гөр килеп чәйләгәннән соңра табын яныннан кузгалышып, Фәһимәне Ульян автобусына озаттык та, атка утырып, сабый чакта яланаяк йөргән Диңгелдә тирәләрен әйләнергә дип чыгып киттек.

Сугыш башлану белән, гаҗәеп көләч йөзле, хәр күңелле Хәлим җизни (авыр
туфрагы җиңел булсын), фронтка китеп, һәлак булгач, шуннан соң озак тормый-
ча Вәсфиҗамал әбиебез дә (җаны оҗмахта булсын), дөнья куйгач, шулар
хәсрәтеннән Зәйделгаян әптәй (авыр туфрагы җиңел булсын) бер башыма ике
олан, аларны ни рәвешле карармын икән, ачка үлмәбез микән, дип кайгы-
ра-кайгыра, үзе дә җан тәслим кыла. Ун яшьлек Мидхәт белән җиде яшьлек
Миңлегөл япа-ялгыз, бөтенләй дә ятим кала. Мохтаҗлыкны, мөгаен, алар миннән
дә ныграк татыганнардыр. Илдә чыпчык үлми, диләр. Бу туганнарым да җан
саклап калу бәхетенә ирешәләр. Тик инде Мидхәтнең эштән бушаганын, урамда
башка малайлар белән шар сугып йөргәнен күрергә туры килмәде. Үсеп җиткәч,
әниемнең киңәшенә колак салып, үзе шикелле үк фәкыйрьлектә үскән кыз бала,
уңган-булган Сәгадәтбану белән гаилә корып җибәрә. Бу инде, карап баксаң, ике
фәкыйрьнең бергә берләшүе түгел, бәлки, берсеннән-берсе уңган ике затның
кушылуы, бербөтен тәшкил итүе була. Акрынлап тернәкләнеп китә болар. Хуҗа-
лыклары үскәннән-үсә бара. Бала-чагалары башлы-күзле була, үз ояларын ко-
рып җибәрә. Хәзер инде төп йортлары — алты почмаклы, шыңгырдап торган өй,
каралты-кура, ике сыер, күпмедер сарык асрыйлар. Өстәвенә әле гомере буе ат
белән эшләгән Мидхәтебез ат та алып җибәрә.

Авылымның бүгенге кыяфәтенә хәйран калырлык. Салам түбәле балчык
ызбаларын табармын димә инде хәзер. Алар урынында йә кирпечтән, йә шыңгыр-
дап торган нарат бүрәнәләрдән өелгән, берсеннән-берсе ямьлерәк, иркенрәк
өйләр. Күбесенең түбәсе дә калайдан, әле сиңа тегенди-мондый гына түгел аның
калае да — цинклы калай. Капка-кура шулай ук тел-теш тидергесез: элеккеге
җилкапкалар гүя җилгә очкан; капка баганалары йә имәннән, йә тимердән булып, капка үзе калай белән, ара-тирә хәтта әле тутыкмас корыч белән тышланган.

Әле кайчан гына авыл халкын үкертеп талыйлар иде ләбаса. Крәстиән хуҗалыгына салына торган салымнарның исәбенә чыгарлык кына түгел иде. Аллага шөкер, авылдашларым зар елаудан туктады, бераз хәлләнеп китте, иркенрәк сулый башлады. Әмма авылның үзендә халык сирәгәя төшкән булып чыкты колхоз эшләре механикалаштырылгач, авылда фәкать комбайн-трактор, ферма-фәлән тирәсендә эшләүчеләр генә торып калды, күпчелек исә, бигрәк тә яшьрәкләр, шәһәр җиренә китү ягын карады.

Якын кардәшләремнең уллары-кызлары барчасы Ульянга барып урнашкан да, шунда башлы-күзле булып, «кадровый рабочий»га әверелгән. Әмма кендекләре авылга бәйләнгән — төп йорттан бөтенләй үк аерылып бетмичә, әти-әниләренә кирәк-яракны җайлап, утын-фәлән ише нәрсәнең хәстәрен күреп торалар икән. Мин кайтканда да берсенең капка төбенә бер машина утын кайтарып бушатканнар, аны кисеп ташлаганнар; икенчесенең өй түренә кисеп-ярып әзерләнгән каен утыны кайтарып аударганнар. Урамда җилләп ята бирә утыннар — кешенекенә тию гадәте юк безнең авылыбызда, юк!

Шулай итеп, авылда карт-коры, минем замандашлар-кордашлар гына яшәп ята, шул сәбәпле, урамнар да тынып калган.

Ичмасам, ике кулына бер эш тә булмагач, кеше дигәнең бит ул күрәләтә ошәнә, һәммә нәрсәгә битараф, барчасына гамьсез карарга өйрәнә. Әкренләп кенә кесәгә шешә керә. Ә инде шешә белән бер дуслашып китсәң, ул сине тиз генә ычкындырмый. Көн башланды исә, ир-атның миен фәкать бер «нужа» кимерә: бүген каян табып салырмын икән, дигән борчулы уй тынгы бирми.

Элекке заманнарда җан рәхәте булган икән: яше-карты сукасын сукалаган, җирен чәчкән, мал-туарын караган, йорт кирәк-ярагын кайгырткан, буш вакытында мәчеткә барган. Һәрхәлдә, җомга намазын калдырмаска тырышкан. Тугыз мәчетнең берсе дә бушап тормаган. Әле унынчысын корырга ниятләп кенә торганда... дингә каршы зилзилә куба, бер-бер артлы тугызының да манарасын кисеп ташлап, барча халыкны зар елаталар...

Элек без укыган җидееллык мәктәп урнашкан ихатага ике катлы менә дигән мәчет корып куйгач кына, кордашларым уйга кала. Инде нишләргә? Мәчеткә йөрмәсәң, кешедән яхшы түгел. Берни эшләп булмый, барырга туры килә, дип кенә, ирексездән, мәчеткә йөргәли башлыйлар. Кызганыч хәл: шешә белән дуслашып өлгергәннәре һич кенә дә эчүдән туктый алмый. Мөгаен, моның шәригать кануннарына сыймаганлыгы аек чакта да башларына керми торгандыр.

Югыйсә бит, дин әһелләренең әйтүенә караганда, хәмер эчкәч, Хода бәндәсе языктан-гөнаһтан кырык көн буена арына алмый икән. Димәк ки, мәчеткә йөрергә бик теләсәң, эчүдән туктарга тиешсең. Ике рәхәт берьюлы килми, ди әдип. Йә тегесен, йә бусын сайлау зарур, башка чара юк. Мәчет карты дигән исем юкка-барга бирелми, шуңа кызыгып, агымга ияреп кенә дәһринең яки эчкеченең мәчет юлын таптавы, миңа калса, иң зур гөнаһ саналырга тиеш.

Бер үк вакытта авылдаш хатын-кызларның йорт-җирне үз җилкәләрендә алып баруына, бала-чаганы һич уфтанмый-нитми тәрбия кылуына, әдәпле-инсафлы булырга өйрәтүенә, хәмердән ерак торуына күз йомып калу һич тә килешмәс. Апалар-сеңелләр, җиңгиләр-киленнәр, шәһәрдәге асыл затлардан үзгә буларак, эчеп-исерү вәсвәсәсенә бирелмичә, әдәпле вә инсафлы булып, яшь буынга чын-чынлап үрнәк булып кала белгәннәр. Югыйсә, шәһәрдә бит төрле хәлләр булгалый. Заманча җиренә җиткереп үткәрелгән эчү мәҗлесендә, әйтик, әүлия булып күренергә маташучы бер ханым, ярыйсы ук мул сыйлангач, сәгатенә күз төшереп алган да:

— Һай! Намаз укыр чагым җиткән икән! — дип, табын яныннан кузгалган һәм:
— Биш вакыт намазымны калдырмыйм, әлхәмделиллаһ, укып барам, — дип сөйләнә-сөйләнә, ава-түнә күрше бүлмәгә юнәлгән. Андый намаз — фәкать күз буяу һәм аның савабыннан битәр гөнаһысы күбрәктер. Калебең саф булып, үзең сайлаган юлдан баруың, кыйблаңа хыянәт итмәвең, үз мәнфәгатеңне генә кайгыртмыйча, бүтәннәргә изгелек эшләп яшәвең — мең артык! Мөхәммәт пәйгамбәрнең Гайшә исемле хатыны үзенең бер ахирәтен диндар итеп күрсәтергә тырышкач, пәйгамбәр:

— Сөйләмә юкны! Һәркем үзе әйбәт белгәнне эшләргә тиеш. Үз эшеңне җиренә җиткереп эшләсәң, Ходайның ризалыгын алырсың, — дигән бугай.

Авылдашларым, кордашларым, газизләрем күңелләренә авыр алмасыннар иде. Мәгәр ава-түнә мәчет юлын таптаганчы, хәлеңнән килгән эшне, фәкать син генә булдыра ала торган эшне, бөтен осталыгыңа фидакярлекне дә өстәп, көчеңне-дәрманыңны жәлләмичә, тәмам җиренә җиткереп башкарып чыгуың, үз калебеңне һәрвакыт саф көенчә, кер кундырмыйча саклавың, бүтәннәргә бертөрле дә этлек эшләмичә, фәкать изгелек кылып яшәвең хәерлерәк булыр.

Авылдагы кордашларым да олыгая төшкәннәр. Колхозга ярты гасыр фидакяр хезмәт күрсәткәннән соң, мөгаен, бераз ял итсәләр дә гөнаһ булмастыр. Әмма уңган-булган авылдашларым тик утыра алмыйлар бугай инде: кадәри хәл кымшану аларның каннарына сеңгән. Шуңа алар мал-туар карау, йорт эшләре кебек нәрсәләрне бик рәхәтләнеп башкаралар. Һәрхәлдә, дилбегәне кулдан ычкындырмау ягын карыйлар. Фәкать яшьләр шәһәрдән кайтып, җимертеп эшләгәнне — хуҗалыктагы бакчаны сөрдереп, бәрәңге утыртып, печән чабып, утын-мазарын кайгыртып, бәрәңгесен казып алып, кышка өйнең хәстәрен күргәч кенә, күңелкәйләре бераз урынына утыра, тынычланып калалар.

(Ахыры бар).

Әхлаксыз йорттан оят качар

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Тагын бер мисал. Мисырдан кайткан татар хатыны белән сөйләшеп утырабыз. Ул: «Бездә ирләр хатыннарын эшләтми, әмма, фәкать үз балаларын тәрбияләү өчен, университетта укытып алалар», дигән иде. Хәер, бездә дә байлар, күпчелек очракта, хатыннарын эшләтмәгән, балаларын укыту өчен өйләренә мөгаллимнәр чакырта торган булганнар. Кайсылары исә кызлар мәктәбе, малайлар мәдрәсәләре ачып җибәргән. Берсендә инсафлы, әдәпле Ил Аналары; икенчесендә үз гадәтләрен югалтмаган, укымышлы ир-егетләр тәрбияләнгән. Безнең хәзерге тәрбия нинди? Балалар бакчаларыннан башлап югары уку йортын тәмамлаганчы, ягъни 20-25 ел буе малае да, кызы да бер казанда кайный. Бала чакта ят, сәер гадәтләр бигрәк тиз йогучан бит әле ул. Әнә шулай чирек гасыр чамасы быкырдатып бергә кайнатканнан соң, гаиләгә керүгә үк кызның бары тик хатын-кызга хас сыйфатлар белән яшәүче күркәм холыклы Ана; егетнең гаиләне туендыручы, хатынын һәм балаларын җил-давылдан сакларга һәрвакыт әзер торучы гайрәтле ир булуын телибез. Димәк, бу турыда да ныклап уйлану кирәк безгә. «Сөембикә» журналы ачып җибәргән кызлар мәктәбе челтәрен киңәйтү — бүгенге көннең үтә дә кирәкле эшедер.

Нәрсә соң ул гаилә? Гаилә тәрбиясе? «Ир белән хатын-кызның никахыннан соң туган бергәлекне гаилә дип булмый. Гаилә дөньяга өченче кеше пәйда булгач — бала тугач кына барлыкка килә», дигән бер фикер иясе. Чынлап та бала белән бергә безнең өебезгә мең шатлык, мең мәшәкать килеп керә. Менә шул шатлык, менә шул мәшәкать безнең тәрбиябез була торгандыр инде. Моңа: Туган тел, Туган җир, Туган нигез, Туган ил дигән төшенчәләрне олылау; Ата, Ана, Ир, Күрше, Сабый хакы дигән сүзләрнең мәгънәсен белү; Иман һәм имансызлык, Хәләл һәм хәрам, Яхшы һәм яман кебек тәгъбирләрнең асылын аңлау һәм тагын бик күп кануннар, йолалар, гореф-гадәтләр керәдер. Кыскасы, әнә шул исемнәр белән аталган әдәп әлифбасын нинди имезлек аша суырттасың бит сабыеңа. Бисмилласыны әйтеп, Туган туфрагында үскән арыш ипекәеннән салган имезлек беләнме, әллә җиде диңгез аръягыннан китерелгән «импорт» кәнфитне чәйнәп биреп ме?

Үткәнне кире кайтарып булмый. Әмма ялгышларыңны белмичә торып, төзәтү мөмкинлеге дә юк. Саный китсәң, ялгышларыбыз, гаеп-кыекларыбыз һай күп булган икән. Иң беренче чиратта безнең динле җаныбызга денсезлек килеп кергән. Аннан мәтрүшкә, гөлҗимеш чәйләре, каз коймаклары исе генә сеңгән өйләребезгә сасы аракы сөремен йоктырган Сөембикәләребезне — Соня, Бәхтиярләребезне — Боря итеп үзгәрткән.

Акылыбызны шайтан алдымы соң? Әллә шаукымга бирелү — милләтебезгә үк хас сыйфатмы? Ник кенә бөтен үткәнебезне сызып ташлап, бик күп кануннарыбызны, гореф-гадәтләребезне аяк астына салып таптарга ирек бирдек без? Әби-бабаларыбыздан «Искелек калдыгы, мәчет картлары» дип көлдек. Оныкларыбызны алар белән аралашудан тыеп, йогышлы чирләрдән «сакладык». Даһи, заман баласы үстерәбез, имеш.

«Аргументы и факты» газетендә чәчләрне үрә торгызырлык бер сан бар. Бездә (Русиядә) хатын-кыз бала тәрбияләүгә төүлекнең 16 минут вакытын бирә икән. Америкада 1 сәгать 23 минут, Франциядә 2 сәгать 15 минут. Безнең аңда бигрәк тә француз кызлары турында йөгәнсез, азгын кебегрәк фикер яши ләбаса. Дөресен генә беләсе иде, 16 минут тәрбияләнгән Русия балалары хакында ни уйлый икән алар? Әллә аларда кеше белән булышу гадәте бөтенләй юк микән? Ничек кенә акланмыйк, гомумиләштереп әйткәндә, бүгенге буыныбыз шәфкатьсез. Тагы да куркынычрагы — кансызлыкның кыз балалар арасында үсә баруы. Бу — нәкъ менә шул 16 минутның җимешедер инде. Балаларыбызны ни олыны олы итәргә, ни гаилә тормышына, ни бала тәрбиясенә, ни эшчәнлеккә өйрәтмәвебез нәтиҗәседер. Гаилә йөген тартудагы түбән әдәп бүгенге көндә аерылышу күплегенә китерүче төп сәбәпләрнең берсе, минемчә. Әйтик, «Байлар да елый белә», «Гап-гади Мария» кебек фильмнарны ник сыерын саумыйча, ашын пешермичә карады хатын-кыз? Ир белән хатынның бер-берсенә кешеләрчә мөнәсәбәтен, гаилә әдәбенең сокландыргыч үрнәкләрен кинода булса да күрер өчен карады ул аны. Гап-гади, әмма гадилектә — галилек икәнен тоеп карады. Әдәпле итеп, бер-береңне хөрмәтләп, саклый һәм кадерли белеп яшәү рәвешенә сусау, бик сусау шул без. Балаларыбызның санлап, исәпләшеп яшәвенә сусау. Җан җылысына, чиста, саф мәхәббәткә сусау. Аек тормышка, ышанычлы кешегә сусау... һәм, ниһаять, үзебезне нәфис җан иясе — хатын-кыз итеп тою мөмкинлегенә сусау!

Күптән түгел күренекле драматург Туфан Миңнуллинның «Җан кисәккәем» дигән пьесасы сәхнәгә куелды. Әсәрнең төп геройлары: бүгенге көн кешеләре һәм шүрәлеләр. Бактың исә, менә шул «урман сарыгы» дип йөртелгән шүрәленең дә хатын-кызга булган мөнәсәбәте кешеләрнекеннән күпкә өстен икән. Бүгенге хатын-кыз әнә шул шүрәле мәхәббәтенә дә сусау бит, егетләр!

Арыдык, бик арыдык кадерсез булып яшәп. Кимсетелеп, кимсенеп арыдык. Тапталып-типкәләнеп, кагылып-сугылып арыдык. Сүгенү, аракы, уйнаш белән тулган киноларны карап; гайбәт, ялган, акыл сатуга корылган тозсыз сүзләрне тыңлап арыдык. Бүгенге күп хатын-кызның бәхетсезлеге, ялгызлыгы — сөя, сөелә белмәгәннән; йә булмаса, ир тәрбияләүгә сәләтсез булганнан түгел. Киресенчә, бик күп ирләрнең гаиләямен, мәхәббәт биеклеген бәяли белмәүдән, аракы яки башка юньсез шөгыльләргә алмаштырудан бит бүгенге әхлаксыз тормышыбыз.

Әнә бит 1993 елда гына Русиядә ирләре, сөяркәләре, йортка керткән ир-атлар кулыннан 14000 хатын-кыз үтерелгән. (Америкадагыдан 20 тапкырга артык). 1994 елда 13000 көчләү очрагы булган. Икенче чыганакларда хатын-кызның соңгы елларда күбрәк үлүе әйтелә. Мәсәлән, берничә ел элек кенә хатын-кыз арасындагы үлем-җитем 965,4 саны белән исәпләнсә, хәзер 1166,4кә күтәрелгән. Төрле сырхауларсыз тиешенчә бала табу да соңгы биш ел эчендә 52,7 проценттан 34 процентка төшкән.

Бала төшерү очракларының күплегә аеруча хәвефле. Аларның бигрәк тә кияүгә чыкмаган яшүсмер кызлар арасында киң таралуы чаң кагар дәрәҗәдә куркыныч. «Чирен яшергән — үлгән», дихалык. Йөрәкләрегезне кысып тотып булса да бу санны укыгыз әле, өниләр: 5333 аборт. Бу унтугыз яшькә дә җитмәгән 1000 кыз-кыркынның 43,3е абортка йөри дигән сүз. Яшүсмерләр арасында эчүчеләр, наркоманнар күзгә күренеп арта. Хәтта 1992 ел белән чагыштырганда гына да 8,4 тапкырга күбрәк наркоманнар яши икән безнең арада.

Хөрмәтле хатын-кыз кардәшләрем, съезд булыр, шаулап-гөрләп узып та китәр. Бик кирәкле, әһәмиятле карарлар да кабул ителер. Әмма ләкин ахырдан шул карарларны тормышка ашыру өстендә дә күңел биреп эшләсәк икән. Үз намусыбыз алдында үзебез хисап биреп, үз вөҗданыбыз алдында үзебез саф калып. Билгеле, теләгән һәммә хатын-кыз съездда катнаша алмас. Ваклыклардан өстен калып, балаларыбызның киләчәге турында уйлыйк. Үз балаларыбызны инсафлы итеп тәрбияләү өчен генә түгел, җәмгыятьне савыктыру өчен яшик. Җәһәннәмнең иң кызу урыны — битарафка, дигән фикер әйтелә Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә. Битараф булмыйк әле!

Күпләребез белә, элек ир бала әти-әнисе каршында эчеп утыру түгел, армиядән йоктырып кайткан тәмәке тартуны да кача-поса эшләгән. Авылның аксакалы урынында йөрерлек акыллы кешенең андыйлар белән ничек сөйләшкәнен минем дә күргәнем бар. Ә хәзер әти-әни армиягә ничек озата улын? Мәҗлес вакытында урындыгыннан егылып төшеп, өстәл астында шуышып йөрү дәрәҗәсенә җиткәнче эчереп. Кыстый-кыстый «сыйлап». Бала алдында киң күңелле булып кылануы бу, йә булмаса юмартлык дип аталамы?

Билгеле, балаңның эчмәвен, тартмавын, өшәке юлда йөрмәвен таләп итәр өчен, иң беренче чиратта, ата-ана үзе яман гадәтләрдән азат булырга, күңелендә борынгыдан килгән аксакаллык сыйфатларын йөртергә тиеш. Димәк, сабый тәрбиясеннән дә элек безгә яшь гаиләләрне күз уңына алырга кирәк икән.

Тормышта: «Әрмән радиосына сорау биргәннәр...» кебегрәк бик күп төрле анекдотлар йөри. Әрмән радиосына түгел, безнең Татарстан хатын-кызларына биргәннәр менә бу сорауны: «Сезнең гаиләдә тавыш ни сәбәпле чыга?». 32,8 проценты — йорт эшләрен бүлешә белмәгәннән, 30,1е — акча мәсьәләсендә, 20,4е — бала тәрбияләүдә уртак фикергә килә алмаганга, 13 проценты бала тәрбияләүдә ирләре бөтенләй булышмаганга, ә 17,5 проценты тавышсыз яшибез, дип җавап биргән. («Тавышсыз» дигәнне дә ике төрле аңлап була бит әле).

Кыскасы, хатын-кызның сәламәтлеге бүгенге көн өчен аеруча кирәк. Чөнки сәламәт ана гына сәламәт бала тудыра, тудырган баласын тиешенчә карап үстерә ала. Тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, сәламәт ана — сәламәт җәмгыять, сәламәт дәүләт, сәламәт кешелек, дигән сүз. Ә Русия ятим-җиллә, гарип-горәбә иле. Картлар йортлары белән тулган дәүләт...

Бүгенге көндә хатын-кыз тормышны ике камыт киеп тарта. Беренче камыт: хөкүмәт эшендә ирләр белән бертигез сәгатьтә, бертигез авырлыктагы йөк тарту булса, икенче камыт, өйдә, йорт мәшәкатьләрен башкарганда; бала үстергәндә. Статистика мәгълүматларына караганда, хатын-кыз йорт эшләренә атнасына 40 сәгать вакытын сарыф итә икән. Ирләр — 14 сәгать. Ике бала үстергән ананың түккән энергиясе иң авыр металлург хезмәтенә тиң. Кыскасы, ат итеп җигелә, сыер итеп савыла соңгы елларда хатын-кыз. Бәлки күргән кадер-хөрмәте дә шуңа бәрабәрдер? Тот капчыгыңны...

Хөрмәтле ир-узаманнар, чын ир-егетләребез, көяңтә-чиләк күтәргәндә дә бәгелеп-сыгылып торган билләребездән алыгыз әле шул авыр йөкләрне! «Безнең Ангелиналар» (мәшһүр тракторчы), дип мактамагыз, ирләр холкы тәрбияләмәгез бездә. Иң яхшысы, мөселман халкының изге җомга көнен ял көне итеп бирсәгез икән. Ә без чыжылдатып коймаклар, өчпочмаклар пешереп, шуллалы бәлешләребезне салып, өйләребезне гөл кебек итеп җыештырып, үзегезне һәм балаларыбызны көтеп алыр идек. Ә ир-атлар хатыннары хакына шимбә көнне эшләсәләр дә, кояш икенче яктан чыкмас.

Җәмгыятьнең, беренче чиратта, ир-атның кемлеге хатын-кызга булган мөнәсәбәтендә күренә. Димәк, съездның җыелуы, дәүләтебезнең, атап әйткәндә, Президентыбызның хатын-кызларга уңай мөнәсәбәтен чагылдыра.

Шулай ук фәкать безнең Татарстан җирлегендә күп һәм яшь балалы гаиләләргә, ялгыз аналарга тормыш дәрәҗәсен күтәрү юнәлешендә Президент Указы нигезендә социаль ярдәм күрсәтү системасы төзелүе һәм эшләве дә — илбашыбызның кешелекле гамәле.

Шулай ук балалары уналты яшькә җитмәгән хатын-кызлар, бары тик безнең Татарстанда, атнага 2 сәгать яки айга 1 көн түләүле ял ала. Ярдәмчесез картлар да бала өмметендә. Картайган әти-әниләребезне, гарип туганнарыбызны тәрбияләр өчен дә шундый ук изгелек эшләнсен иде. «Файдалары» тими башлаган әти-әниләребезне картлар йортларына илтеп, бәддогаларын алмасак икән.

Хатын-кызлар съезды алдыннан кайбер фикерләрем белән уртаклашырга алынганмын икән, аеруча мөһим дип уйлаган тәкъдимнәремне, шәхсән Сезгә эндәшеп әйтәсем килә, Минтимер Шәрипович!

1. Сез җитәкчелек иткән дәүләттә 3727000 кеше яши. Шуларның 1988054е хатын-кыз. Ә сәламәт хатын-кыз — сәламәт Ана, сәламәт бала, сәламәт дәүләт. Сез идарә иткән еллар — Татарстан тарихына — **Дәүләтне савыктыру чоры** булып теркәлсен иде!

2. Киләчәкнең зыялы милләт Аналарын тәрбияләү өчен күпләп **Кызлар мәктәпләре** ачуның кичектергесез эш икәнлегенә тагын бер кат басым ясыйсым килә.

3. Тәрбия, гаилә мөнәсәбәтләрен юлга салуның бүгенге көндә иң беренче эш икәнен истә тотып, татар телендә «Семья и школа» кебек **журнал чыгара башлау** кирәк. Татарстан телевидениесе буенча ашыгыч рәвештә нәкъ шушы максат белән эшләүче **даими тапшырулар циклы** оештыру зарури.

Киләчәктә хатын-кызның хәл-хәятен яхшырту, җәмгыятьне савыктыру, милләтебезне асылына якынайту юнәлешендә съездга уңышлар телим.

Чулпан ЗАРИФ

Шагыйрь нечкәлек билгесе белән языла

«Гарәп аһәңнәре»

1

Пәйгамбәр халкының бары тик бер улы...
Ә күпме, күңелдә, гамь илә моң туды!

Учыма салдым да, күзләдем йөрәкне:
Ул халык сөйсәме!.. Әйтмәдең — «кирәкми...»

Диңгез дә үлгән бит (ай, тозлы сулары!)...
Сәбәбе ни иде? Белде соң кем аны?..

Хиҗаздан искән җил, эль-фәрид әйтмешли,
Бигрәк тә еракка ташласа, йә, нишлик?..

«Йөридер шагыйрьләр, үтәми сүзләрен...» —
Мин бүген үземне шул илдән эзләдем.

Бары тик бер улын сөйдерде пәйгамбәр,
Шул көннән бу җирдә күпме дәрт һәм гамь бар...

2

Биш намаздан калган дәрвиш, күреп төрки күзләрне.
Үткән гомер... Соң ул күзләр — әллә бүген үзгәме?!

Гонаһка кермим, ташладым бер генә караш, ни хәл! —
Бер генә Аллага өмет тәсбихыңны өзгәнмен...

Иблис үзе биргән мәллә сөйдерүдә фатиха:
Күңелеңне яулап, күр, китердем астын өскә мин.

Җиде көнгә сынап безне, бәйрәм көткәндә җиһан —
Сиңа сөю дигән хистән яңа тәсбих тезәмен...

3

Т[illegible]елгәнгәме капчыгы фәрештәнең, кем белә —
Бөтен җиргә дигән ташлар бары сезгә сибелгән...

Шул ташларны җыяр вакыт җиткәнен әллә сизеп,
Калфак кигән газиз башым алларыңа иелгән.

Җарашның баганасы күк, тирбәлә күңелем кылы.
«Кеше бит көчсез, бик йомшак яратылды», — диелгән...

Күкрәктә кургаштай авыр дулкыннар ята тынып,
Бәхр-лут көчкә күтәрә, мин ничек түзим икән?..

Куркам, бу кадәр янудан, бу кайнар сулышыңнан
Арихон гөлчәчәгедәй әйләнеп калсам көлгә?!.

Җәбәл-әл-нәби тавыннан эзләдеңме син мине?
Кайчан соң әле ул таудан туган илем күренгән?!

Мисырдан Болгарга йөрткән кәрваннар юлы, бәлки,
Мәликләр юлы... Шундамы җаннарыбыз үрелгән?..

* * *

Ак дөягә менсәң иде, сахралар кичсәң иде ул,
сахралар кичсәң иде!
Сөю мәңге китмәсен дип, комнан бау ишсәң иде ул,
комнан бау ишсәң иде...

Диңгезләргә төшсәң иде, энҗеләр тезсәң иде ул,
энҗеләр тезсәң иде!
Бер генә коеп күз яшен, мең еллар көлсәң иде ул,
мең еллар көлсәң иде...

Оҗмахка кереп, алманы бер генә өзсәң иде ул,
бер генә өзсәң иде!
Җиргә куылганнан ары, күкләргә төшсәң иде ул,
күкләргә төшсәң иде...

* * *

Йә, Ходаем! Йә, Ходаем! Ник күңелдә шундый тынлык,
Нигә йөрәк белән икәү кинәт кенә тынып калдык?

Нигә газиз башкаемны, авыр сулап, учка алдым,
Нидән күңелсезләндем дә, нидән болай уйга калдым?

Тыным чыкмый, өзүемнән учка тама күз яшьләрем...
Нәрсә эшлим, нигә кирәк миңа синсез бу яшьләгем?!.

* * *

Кояшка юл тота кәрваным. Аралар якынрак көннән-көн.
Әйләнеп кайтмасам, кичерерсеңме соң, илаһи сөеклем?

Талчыккан дөяләр янымда чайкалып баралар;
Көннән-көн ешая шатлыклар, кимиләр моң-зарлар.

Кояшның нурлары — күрәмсез, дөяләр! — Эрегәләр безне...
Синең күк янам мин, әй кояш!
Җылытырмын микән, кешеләр, мин сезне?!.

* * *

Өстемдә кызыл, кояшлы, ак торналы кимоно.
«Күр, ничек ошыйсың миңа!» дип әйтмисең ник аны?!
Сөрмәле күзләр... Иренгә кем өчен иннек сөртәм?
Мин эндәшмим. Син бу хакта сорама, берүк, бүтән...

Төн инде. Ай да юк, эт тә уламый бер булмаса.
Бар да йоклый. Төн эчендә яшим шулай лабаса.
Караватымда сузылып йоклый кап-кара мәчем.
Яшиммени?!
Үлеп барам... Тоела гына — яшим...

Кайтар, Баку!..

Баку! Сиңа кайтам әле мин бер,
Сагындыра зәйтүн-нарларың.
Синең диңгез буйларыңда йөреп,
Көннәр буена һич армадым.

Кыз каласы нинди горур, бөек!
Тик, гел таштан. Ә мин җанлы шул.
Ташка нәрсә — минем янып-көеп,
Мәхәббәтем белән кавышу?!

Түземле дә, кызу да син, Баку,
Утка табынганнар җирендә...
Сулар сипкәч, сүрелде дә ялкын,
Диңгез тәме калды ирендә.

Ширваншаһлар узган юлларында,
Буш тынлыкта эзлим кемнәрне?
Баку! Сиңа булсын барлык җырларым да,
Ә син кайтар үткән көннәрне!..

* * *

Кара мәчем, зарланма соң ул кадәр!
Бу әрнүләрем дә үтәр бер... әгәр
Бүген исән калсам — яшим иртәгә.
Күз яшьләремне күрмәсен башкалар...

Кызганма син мине ул кадәр, мәчем.
Төшмәгән бит башымнан әле таҗым!
Төшсә дә... әлбәттә, югалту — ачы,
Ләкин исәнлектә горур баш кала!

Түзик бераз... шатлыклар, бәлки, алда.
Түзик бераз. Зарланма, кара мәчем...

* * *

Калфак кидем әле башыма,
Ничек түзәрсең карашыма?!
Яшерепме синнән уйларымны,
Җирән чәчем төшкән кашыма...

Калфак кидем, чия төслесен...
Узекләрең, әйдә, өзелсен.
Күңелемнең айдай тулган чагы,
Тик... көләсем килә, көләсем!..

Уфаларда чиккән калфагым
Хәтерләттеме оҗмах багын?
Без ул багтан инде куылсак та,
Алмага дип үрелә́м тагын!

Ә башымда чия калфагым...

Елама син, җил

Агач башына менгән дә,
Җил елый үкси-үкси...
Йә, елама соң, миннән дә
Ялгызрак түгел лә син.

Тош яныма, җылы сүзләр
Әйтеп юатам үзем.
Бирешергә иртә безгә,
Минем кебек бул түзем...

Иң яшь кандидат

Ирек МОРТАЗИН

1964 елның 5 апрелендә Татарстанның Саба районында туган. 1981 елны Иске Чүпрәле урта мәктәбен алтын медаль белән тәмамлый һәм Казан танк училищесына укырга керә. Аны уңышлы тәгәлләгәч, Ленинград һәм Кавказ арты хәрби округларында башта взвод, аннары батальон командиры урынбасары булып хезмәт итә. Ләкин, Баку вакыйгалары вакытында армияне тыныч халык белән көрәштә файдалануга каршы чыккач, 1990 елда хәрби хезмәттән китәргә мәҗбүр була.

Шушы вакыттан И.Мортазинның журналистлык эшчәнлеге башлана. 1995 елның маеннан ул «Молодежь Татарстана» газетасының баш мөхәррире урынбасары. Урысча «Әфган көле» исемле китабы басылган.

И.Мортазин 1995 елда читтән торып, Мәскәү дәүләт юридик академиясен тәмамлый. Алты елга исәпләнгән программаны ул өч елда үтә. Хәзерге вакытта «Оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәшнең икътисади алымнары һәм шартлары» дигән темага диссертация яза.

Мәгълүм сәясәтче Григорий Явлинскийның тарафдары. «ЯБЛОКО» җәмәгать берләшмәсенең үзәк советы әгъзасы.

И.Мортазин спорт белән дә тегләп һәм уңышлы шөгыльләнә. Ул шахмат, җиңел атлетика, чаңгыда узышу һәм башка кайбер төрләр буенча мастерлыкка кандидат, беренче разрядлы спортчы дәрәҗәсенә ия.

Татар, урыс, чуваш, немец телләрен белә.

Өйләнгән. Ике баласы бар.

КӨТКӘН ДУМА ХӘЗЕР ТУАР, ЛӘКИН ДУМАГА КЕМ ТУЛАР?

Бу юлы да алданма, татар!

Русия Дәүләт Думасына сайлаулар якынлаша. Депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән халык вәкилләре арасында Бөтенрусия «Нур» мөселман иҗтимагый хәрәкәте кандидаты — танылган язучы Айдар Хәлим дә бар.

— Безне, әлбәттә, беренче чиратта Сезнең иҗатыгыз кызыксындыра. Соңгы вакытта иҗат белән шөгыльләнә алдыгызмы? Әллә сайлау алды мәшәкатьләре бөтен вакытыгызны аламы?..

— Иҗат — минем төп эшем. Күптән түгел укучыларга мәгълүм «Книга печали или записки аборигена» дигән китабымның дәвамын — икенче өлешен тәмамладым. Ул шактый күләмле (50 табак чамасы) әсәр булып чыкты. Бу китабымны мин соңгы 20 ел эчендә татар һәм төрки дөньясында булган социаль һәм милли-мәдәни үзгәрешләрне анализлауга багышладым. Һәм ике сорауга: «Кем идек — кем булдык?» «Милләт бармы, әллә ул юкмы?» дигән сорауларга җавап бирергә тырыштым. Китап әзер. Аның бер өлеше «Казан утлары» журналының быелгы 6 нчы санында басылып чыкты. Китапны язганда кулыма йөзләгән фотосурәтләр, документлар килеп керде. Аларның күпчелеге матбугатта беренче тапкыр басылачак. Укучыларыма алдан ук әйтеп куясым килә: китапның иң кызык бүлекләренең берсе «Татар милләте һәм КГБ» дип атала. Кайбер бүлекләрнең исемнәре мондый: «Башкаларга баш бирмәгән башкорт», «Таң вакыты. Татар йоклый», «Нечкә» милләт турында тупас уйлар». Соңгы бүлектә Җир йөзендә калган бердәнбер, иң өшәке неоимпериализм баткагыннан урыс һәм башка милләтләрне ничек чыгару юлларын күрсәтергә омтылдым. Китапны татар, башкорт һәм урыс милләтләренең һәркайсын милләт һәм дәүләт буларак саклау өчен кануннамә (катихезис) дип тә кабул итәргә мөмкин.

— Айдар әфәнде, сайлауларга бик аз вакыт калды. Гомуми вәзгыятьне ничегрәк күзаллыйсыз?

— Әгәр бу сайлаулар Татарстан мөстәкыйльлеге өчен көрәшнең 1990-1993 еллардагы шартларында узган булса, әлбәттә, сайлауларга бойкот игълан итү дөрес булыр иде. Кызганыч ки, 1994 елның 14 февралендә Русия һәм Татарстан арасында кабул ителгән Шартнамә безнең хәлне яхшыртмады. Минем фикеремчә, бәлки ялгышамдыр, Татарстан Республикасы үз тәрәккыятендә элеккеге автономия шартларындагыдан да түбән сәяси вәзгыятькә килеп керде. Татарстанда милли азатлык хәрәкәте оешып китә алмады. Бездә милли азатлык хәрәкәтен, киң мәгънәдә әйткәндә, юк дип исәпләү дөресрәктер. 1991-1993 елларда Русия басымыннан чагыштырмача азатрак булган Татарстан бүген Мәскәү номенклатурасының, килделе-киттеле семинарларын үткәрү битлеге астында, ашап-эчеп, сыйланып китү урынына әйләнде. Шуңа күрә, минем фикеремчә, «без — суверен дәүләт», «без сайлауларга катнашмыйбыз», дип коткы тарату, болай да консервация шартларында яшәгән, Актаныш һәм Мөслимнең бәрәңге плантацияләреннән чыкмаган татарны сәяси көрәш тәҗрибәсеннән читләштереп, аны мич башында йоклату белән бер.

Сайлаулар үтәчәк. Депутатлыкка татарның бүгенге тормышын җиңеләйтү, мөстәкыйльлеген ныгыту өчен көрәшәчәк вәкилләрне сайлау зарур. Сайлауларда кандидат итеп теркәлгән бөекдержавачыл, христианчыл, трансмилли-шовинистик һәм турыдан-туры фашистик хәрәкәтләр арасында татар һәм бөтен төрки, мөселман милләтләр һәм аз санлы халыклар мәнфәгатен яклаучы бердәнбер «Нур» мөселман иҗтимагый хәрәкәте изге максатлары белән аерылып тора. Аның үз мәсләгенә тугрылыклы булачагына иманым камил. Федераль бюллетеньдә безгә татар өчен изге булган 7 саны чыкты. Бюллетеньдәге шул 7 санына билге куюыгызны сорыйм. Һәм төрле хәрәмләшүләргә юл калдырмас өчен бюллетеньнәрне дөрес тутыруга зур игътибар бирсәгез иде.

— Айдар әфәнде, безне кызыксындырган тагын бер сорау бар. Сезнең «Аргамак»тан китүегез турындагы хәбәр дөресме?

— Әйе, дөрес. Моннан ай ярым элек, «Нур» хәрәкәтеннән 24 нче Чаллы округы буенча депутатлыкка кандидат булып чыгу өчен имзалар җыюым билгеле булгач, Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы Р.Алтынбаев әфәнде бөтен шәһәр җитәкчеләре катнашкан дүшәмбе киңәшмәсендә сайлау комиссиясе җитәкчеләре алдында саф урыс телендә миңа күрсәтмә бирде: «... пусть А.Халим не лезет в большую политику. Пусть он пишет книги». Мин сайлаучылардан 7 меңгә якын имза җыйдым (5030 имза да җитә иде). Бер мандатлы Чаллы округы буенча бер урынга төрле партия һәм хәрәкәтләрдән 9 кандидат булып, мин бердәнбер татар, мөселман кешесе идем. Сайлау комиссиясе (рәисе Р.Йосыпов) мине — бердәнбер мөселман кандидатын теркәүдән баш тартты. Андагы кандидатларның сайлау алды программалары белән таныштым мин. Аларда Татарстан халыклары бәхете өчен көрәшү омтылышы юк дип исәплим. Минем бер үк вакытта «Нур» хәрәкәтенең федераль исемлеге буенча кандидатлыкка баруымны белгәч, рәсми җитәкчелек юлыма икенче киртә куйды: «Аргамак» журналын чыгаруны яңа 1996 елдан башлап хуҗалык исәбенә күчерергә тәкъдим итте. Бу инде күрәләтә басым ясау дигән сүз. Мин, гариза язып, эштән китәргә мәҗбүр булдым. Депутат булып эшләүне бүген кирәгрәк эш дип саныйм.

— Сайлаучыларга нинди теләгегез бар?

— Безнең максат изге: парламентта татар һәм төрки халыкларның хокукларын яклаган законнар кабул итү, Дума мөнбәреннән торып мөстәкыйльлегебезне яклау; халкыбызны Ислам нигезендә тәрбияләү, рухи тазарыну-чистарынуга илтү. Теләк шул: сайлаучылар үз тавышларын партия һәм блоклар бюллетенендәге бер генә хәрәкәт — «Нур» кандидатларына бирсеннәр иде!

Сайлауларга бармый калу һич ярамый. Бу юлы алданмасаң иде, татар!

Әңгәмәне **Салисә ГӘРӘЕВА** үткәрде.

КАРАШ

Күпчелек азчылыкка буйсынырмы?

Әле быелның җәендә генә минем Русия Дәүләт Думасына сайлауда катнашырга теләгем бар иде. Мондый теләк миндә империя парламентында гына түгел, Русия Президенты тирәсенә тупланган шовинистик карашлы бәндәләрнең бөтен республикаларны бетерергә һәм аларны гади урыс губерналарына әверелдерергә дигән мәсьәләне алга сөрүләреннән килеп чыкты. Әгәр дә без яңа Думага Татарстаннан кыю һәм милләткә турылыклы депутатлар сайласак, алар анда, Мәскәүдә, республикабызның мөстәкыйльлеген бөекдержавачыл депутатларның кизәнүләреннән яклый алырлар дип уйлый идем. Ләкин сайлау көне якынлаша башлагач, минем уй-фикерем бөтенләй үзгәрә башлады. Тора-бара бу сайлаулар безгә, татарларга берниндн дә файда китерә алмас дигән нәтиҗәгә килдем ми

Үзегез уйлап карагыз: әгәр дә без Русиянең яңа Думасына бер дә каушамый торган, бер нәрсәдән дә курыкмый торган депутатларны гына сайласак та, барыбер бу биш-алты кеше урыс патриотик хәрәкәтләреннән һәм Русиянең өлкә яки крайларыннан сайланган депутатларга каршы тигез көрәш алып бара алмаячак. Урыслар Думаның ким дигәндә 85 процентын тәшкил итәчәк бит. Аларның күпчелеге Русиядә республикаларны бетерү позициясендә торачак. Моның шулай булачагына мин аз гына да шикләнмим.

Форсаттан файдаланып, менә нәрсә әйтәсем килә мине безнең кайбер милләттәшләребезнең Русия парламентына ничек булса да әләгергә омтылулары гаҗәпләндерә Менә мөхтәрәм Р.Сиражиев әфәндене генә алыйк. Элекке Татарстан Югары Советы депутаты бүген Русия парламенты депутаты мандатын алыр өчен хәзерге Дәүләт Думасының рәисе Иван Рыбкин блогына керде. Бу ничек шулай килеп чыкты соң әле? Әллә Р.Сиражиев шул ук Рыбкинның 1995 елны, кирәк булса, Чечня вариантын Татарстанда да, Башкортстанда да кабатларбыз, дип янаганын онытып җибәрдеме?

Рыбкинны мәшһүр хокук яклаучы Лариса Богораз «Общая газета»ның алтынчы санында фаш итеп чыкты. Бу курку белмәс һәм намуслы урыс хатынының кыюлыгына мин сокланам һәм аның алдында баш иям.

Милләттәшебез Айдар Хәлимнең узган елларда татар халкы мәнфәгатьләрен яклап армый-талмый көрәшкәнен без бер дә онытмыйбыз. Ләкин шушындый акыл иясенең үзен Русия Думасына Бөтенрусия «Нур» мөселман хәрәкәтеннән Думага депутат итеп сайланырга теләве мине чын-чынлап гаҗәпләндерә. «Ватаным Татарстан»да басылган (17 ноябрь саны) мәкаләсендә Айдар Хәлим әфәнде «Дума трибунасыннан татар мөселман дәүләтчелеге, мөстәкыйльлеге өчен гадел һәм чигенмәс көрәш башлап җибәрә алыр идек», ди.

Мин XX гасыр башында Русиянең беренче, икенче һәм өченче Дәүләт Думасы мөнбәреннән татар зыялыларының мөселман фракциясе депутатлары буларак татарның мәнфәгатен яклап чыкканнарын бик яхшы беләм. Ләкин 90 процентган да артык булган урыс депутатларының бик күпләре безнең милләт депутатларының чыгышларын әзгәннәрен, алардан көлеп утырганнарын да Айдар Хәлим исендә тотсын иде. XX гасырның ахырында да Дума залында утыручы урыс депутатлары (алар Русия парламентында күпчелекне тәшкил итәчәк депутатлар) тарафыннан безнең депутатларга шундый ук мөнәсәбәт булмагае, дип уйлыйм. Шуңа күрә, Айдар әфәнде Дума мөнбәреннән татарны ничек кенә якларга тырышса да, бу изге эштә аны бары тик уңышсызлыклар гына көтәр шикелле.

Илдар СИБГАТУЛЛИН.
Казан.

Сөйләшүгә чакырабыз

Флүн МУСИН,
академик

Әдәбиятыбызны хәзер ничек өйрәнергә?

Хәзерге күпсанлы гәзит журналларның инде байтагына язылырга матди мөмкинлек булмагач, аларның өйгә алдырылмаганнары белән кайдадыр уку залында яки башка берәр урында бераз соңлабрак танышырга туры килә. Күптән түгел шундый басмалардан берсенең соңгырак саннарын карап утырганда мин бер язмада үземне сискәндереп җибәргән фикергә тап булдым. Анда язманың төп темасыннан читләшеп һәм ничектер үтеп барышлый гына хәзер совет чоры әдәбиятларын өйрәнүдә һәм бәяләүдә башланган гомум яңарыш хәрәкәте, имеш, 1917 елдан соң безнең илдә алып барылган «барлык үткән мирасны себереп түгү» кампаниясе белән аваздаш диебрәк бәяләнә. Бер яктан, монда совет властеның беренче елларында да мираска мөнәсәбәт артык каралтып күрсәтелә, нәтиҗәдә мәсьәлә белән тирәнтен таныш булмаган укучыларда Октябрьдән соң элекке әдәби хәзинәләр бөтенләй себереп түгелгән икән дигән ялгыш фикер туарга мөмкин. Икенче яктан, хәзерге вакытта 1917 елдан соңгы әдәбиятны яңача өйрәнү омтылышын үткәндәге пролеткультчылык ниятләренә тиңләштереп карау бүгенге фәнни эзләнүләрнең асылын аңламау тәэсирен калдыра. Әйтергә кирәк, шушы сәбәп аркасында әдәбият тарихын яңартып өйрәнүгә һәм укытуга да шикләнеп яки өнәмичә караулар белән моңа кадәр дә очрашкалаган бар иде. Мисал өчен элекке еллар рухында тәрбияләнгән кайбер өлкән яшьтәге кешеләр арасында. Әмма соңгы очрак мине элгәреләренә караганда ныграк сәерсендерде һәм сискәндерде, чөнки әлеге сүзләр фән даирәләрендә мәгълүм кеше тарафыннан әйтелгән иде...

Әдәбият фәне мәсьәләләреннән читтәрәк торган укучыларда әдәби тарихны, бигрәк тә аның совет чорын яктырту өлкәсендә алып барыла торган эзләнүләргә шундый ялгыш караш тумасын өчен, мин, әлеге эзләнүләр белән башлап шөгыльләнүчеләрнең берсе буларак, әдәбиятыбызны хәзер ничек өйрәнергә һәм өйрәтергә кирәклеге турында үземнең гомумирәк характердагы кайбер уй-фикерләрем белән уртаклашырга булдым.

Әдәбиятыбыз тарихының башка дәверләре кебек, аның совет чорын да яңача яктырту мәктәптән башланырга тиеш. Чөнки мәктәптә балаларга аң-белем һәм тәрбия бирүдә, бигрәк тә аларны милли рухта тәрбияләүдә әдәбиятка мөһим роль йөкләнә. Ә бу рольне уңышлы башкару байтак дәрәҗәдә сүз сәнгатен чын фәнни нигездә яктырту белән бәйләнгән. Балаларны шул рәвешле әдәбият белән тәрбияләү эше башланып та килә инде. Шушы күркәм эшкә хезмәт итүче яңартылган мәктәп программалары һәм дәреслекләрнең фәнни хезмәтләргә караганда тизрәк дөнья күрүләре сәбәпле, әдәбият тарихын яңача яктырту өлкәсендәге эзләнүләр дә киң җәмәгатьчелеккә иң элек шулар аша барып җитәрләр кебек. Шунлыктан, 1917 елдан соңгы әдәбиятыбыз тарихын яңача яктырту турында уйланганда да, әлеге программа белән дәреслекләрдән әтәрелеп китәсе килә. Әтәрелеп кенә, чөнки бу хезмәтләр махсус сөйләшүне сорый, ә биредә андый максат алга куела алмый. Бары шуны гына әйтәсе килә: программа белән дәреслекләргә өстән генә күз ташлаганда да, аларда әдәбиятны хәзерге ихтыяҗ-таләпләрдән чыгып укыта башлауда инде кызыклы күзәтүләр, үзгә адымнар булу белән бергә, гомумән алганда, яңарышның әле җиңел генә бармавын да күрәсең. Барыннан да элек, монда гомум методологик мәсьәләләрнең хәл ителмәгәнлеге үзен сиздерә. Бу нәрсә инде иң өстә яткан күренешләрдә, мисал өчен әдәбият тарихын чорларга бүлүдә һәм аларга исем бирүдә үк күзгә ташлана. Әйтик, әлеге программа белән дәреслекләрдә 1917 елдан башланган әдәби хәрәкәтнең әүвәлге чорын вакыт ягыннан билгеләүдә һәм аны исемләүдә буталчыклык бар. Мәсәлән, 10 нчы сыйныф өчен дәреслек-хрестоматиядә бу чор Октябрь революциясеннән 1922 елга кадәр вакытны эченә ала дип күрсәтелсә һәм аңа «Гражданнар сугышы еллары әдәбияты» дигән исем бирелсә, программада исә ул Февраль революциясеннән алып гражданнар сугышы ахырына кадәрге дәверне колачлый. Бу соңгы бүленешне исемләүгә килсәк, программаның 1992 елгы басмасында ул «Пролетариат диктатурасы чоры татар әдәбияты» дигән исем йөртсә, хәзер яңартып басуга әзерләнгән вариантында исә аңа «Совет хакимияте башланганда татар әдәбияты» исеме бирелгән. Әйтергә кирәк, бу исемнәрнең икесе дә фәннилектән шактый ерак торалар, публицистик яки социологик рухлылар. Алга таба «20 еллар әдәбияты», «30 еллар әдәбияты», «40-50 еллар әдәбияты» дигән классиграк формадагы исемнәр бирелсә дә, 60 елларга килеп җиткәч, кабат баштагы хисси-публицистик исемләүләр китә. Болар, әйтик, 60 елларда чыгарылган «Татар совет әдәбияты тарихы»ндагы (урыс телендә) «Татар әдәбияты — социалистик төзелештә актив катнашучы», «Туган илнең намусы һәм бәйсезлеге өчен сугышларда», яки «Тыныч хезмәт һәм коммунизм төзелеше байрагы астында» кебек купшы, чуар һәм хисси исемләүләр белән шактый аваздаш яңгырыйлар.

Ә менә искә алынган әдәби чорны Февраль революциясеннән башлау тарихи һәм эстетик яктан аклана дип әйтәсе килә. Алай гына да түгел, ул зур игътибарга лаек һәм принципиаль фәнни әһәмияткә ия. Әмма аны әле ныклап нигезләргә кирәк. Монда да фәнни тикшеренүнең заманча методологик принципларын ачыклау ихтыяҗы сизелә. Чөнки бу эштә хәзер үткәндәге сыйнфыйлык һәм партиялелек принципларына мөрәҗәгать итү үзен акламаячак. Аларга таянсаң, әдәбият тарихын элеккечә яктыртырга туры киләчәк. Бу тарихны дөресрәк күзаллау һәм күрсәтү өчен, минемчә, беренче чиратта тарихилык белән миллилеккә нигезләнү отышлырак булыр. Чөнки нәкъ менә шушы принциплар туган әдәбиятыбызның XX йөздәге яшәешен татар дөньясындагы үзгәрешләр белән тыгызрак бәйләп карауны сорыйлар.

Мәгълүм ки, 1905 елгы революциядән башлап бу дөньяда милли азатлык идеясе һәм хәрәкәте байтак вакытлардан соң кабат әйдәп баручы көчкә әверелә. Шул нигездә татар милли идеясе дә көчәеп китә. Табигый, болар барысы халык яшәешенең һәм күңеленең үзенчәлекле елъязмасы, көзгесе булган әдәбиятка турыдан-туры йогынты ясый һәм аның үсеш юлларын да билгеләүдә катнаша. Февраль революциясе халкыбыз күңелендә күптән яшәп килгән милли азатлык һәм хөрлек хыялының, ниһаять, тормышка ашырына ныклы ышаныч тудырган иде. Моны әдипләр бик тиз сизел алдылар. М.Гафури, мәсәлән, әлеге революция белән рухланып, «Татар байрагы» дигән шигырен иҗат итте. Татарның дүрт йөз елдан артык көтелгән азатлык, бәйсезлек көне, ниһаять, килде дигән куаныч белән язылган бу шигырьне әдәбиятыбызда яңа тарихи дәвер башлануын хәбәр иткән беренче карлыгачлардан дип карарга мөмкин. Әгәр «Татар байрагы» Февраль вакыйгаларының кайнар эзеннән әсәрләнеп язылса, Ф.Әмирхан исә үзенең «Март каһарманы»н әлеге вакыйгалардан соң берничә ай үткәч һәм инде шактый «айнып» иҗат итә. Шул хисләр бик куерган эмоциональ вакытка талантлы әдип хәзер аек күз белән карый һәм хезмәт кешеләренең ирекле тормышка омтылуын төрле сәяси көчләрнең үз мәнфәгатьләрендә файдаланып калырга ашыгуларын күрә. Әлеге хезмәт халкының азатлыкка, милли мәнфәгатьләрен канәгатьләндерергә омтылышы бермә-бер көчәйгән һәм бу омтылышның тормышка ашу мөмкинлеге дә арткан көннәрдә аны яратучы, аңа хезмәт итәргә теләүче «дуслары» кинәт күбәеп китә. Ул вакытта модага әверелдерелгән «милләтче», «социалист», «революционер», «демократ» һ.б. исемнәр астында чыгыш ясарга яраткан халык «дусларының» типик вәкиле итеп Ф.Әмирхан үз әсәренең гәрое — «милләт каһарманы» Гыйсмәтулланы күрсәтә. Шул чорның халык азатлыгы һәм бәхете өчен көрәш лозунглары белән «кораллanып» һәм һәртөрле митингларда үтә хисле «милли», «революцион» чыгышлар ясап, Гыйсмәтулла тиз арада «кырык төрле демократия мөәссәләрендә (оешмаларында) әллә ничә төрле лөзүме шигаль итүче (вазифа башкаручы) демократия «лидерына» әверелә. Һәм халык мәнфәгатьләрен «кайгыртучы» күпсанлы «милли», «демократик», «революцион» оешмалардан зур гына «жалуния» ала башлый. 1917 елның август аенда язылган бу әсәренең ахырында Ф.Әмирхан 1920 елда Русиядә кушма җөмһүрият, ягъни милләтләр конфедерациясе төзелеп аның үзәк хөкүмәтенә татарлардан бер социалист сайлануын фараз итә, «ләкин ул социалист безнең Гыйсмәтулла түгел иде», ди.

Язучының февраль белән октябрь аралыгында Русиядә булган хәлләргә мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан «Март каһарманы»ның исемастындагы үзгәрешләр бик тә игътибарга лаек. Беренче тапкыр «Аң» журналының 1917 елгы сентябрь санында басылганда автор аңа «Вакыйгага пародия» исемасты бирә. Ягъни моның белән әдип ул вакыттагы Гыйсмәтулла кебек күпсанлы халык «дуслары»на үзенең чын мөнәсәбәтен белдерә. Ф.Әмирханның «Көлке вә һөҗү хикәяләре» җыентыгында (Уфа, 1918) исә әлеге хикәягә инде алдарак искә алынган «Язылган вакытта шарж иде, Октябрь ахырында фактка әйләнде» дигән исемасты бирелә. Монда инде әдипнең 1917 елгы Октябрь вакыйгаларына, аларны оештыручыларга мөнәсәбәтен чамаларга мөмкин. Әлеге исемастыннан большевикларны Гыйсмәтулла кебек шарж «геройлар»ының гамәлләрен дәвам итүчеләр итеп карауны һәм аларның, купшы вәгъдәләр белән халыкны үзләренә каратып, үз максатларына ирешүләренә ишарә ясауны сиземләргә була.

Кыскасы, М.Гафуриның «Татар байрагы» шигыре белән Ф.Әмирханның «Март каһарманы» хикәясе татар әдәбиятының Февраль революциясеннән башланган яңа дәверенең беренче үрнәкләре һәм аның төп юнәлешләренә нигез салган әсәрләр дип карала алалар. «Татар байрагы» белән бәйле беренче юнәлеш әлеге дәвер әдәбиятында заман тормышын хисси-романтик рухта күрсәтүгә караса, «Март каһарманы» чынбарлыкка аеграк карап һәм тәнкыйтьчел пафос белән яктырту юнәлешенә нигез салды.

Әйтергә кирәк, совет заманында бу юнәлешләрнең яшәү мөмкинлеге һәм язмышы төрлечә булды. Рәсми идеология совет системасын пропагандалау максатында беренче юнәлешкә киң юл ачты, ягъни совет чорында әдәбиятта заман чынбарлыгын хисси-романтик планда чагылдыру өстенлек алды. Икенче юнәлеш исә, большевистик яки коммунистик идеология максатларына каршы килүе аркасында, әдәбиятта рәсми төстә яши алмады, шунлыктан үзен күбрәк эзоп теле белән яки йөзен яшеребрәк кенә сиздерә алды. Бу хәл әдәби иҗатта икекатламлылык күренешен, дөресрәге, тенденциясен хасил итте. Ачыграк әйтсәк, әдәби әсәрнең идея-эстетик эчтәлеге еш кына ике катламнан тора булып чыкты. Әллә каян күзгә ташланып торучы өске катлам нәкъ менә бездәге идеологиягә хезмәт итә иде. Ягъни анда рәсми идеология алга куйган идеяләр һәм мәсьәләләр яктыртылды. Икенче, аскы катламда исә нигездә авторның үз теләгәне чагылыш тапты. Сүз уңаенда кайбер әдипләрнең күңелендәгесен әсәрләренең үзләре өчен генә язылган кульязма вариантларында чагылдыруларын да әйтергә кирәк. Мисал өчен бу алымга Һ.Такташ әледән-әле мөрәҗәгать иткән. Заман темасын яктырткан кайбер әсәрләренең басылган, ягъни рәсми төс алган вариантларында ул үз чоры рухындарак фикер йөртсә, кульязма хәлендә шәхси архивында калган вариантларында исә үзе теләгәнчә фикерли кебек.

Әлеге «ике катламлы» әсәрләрнең вакыт сынавын үтәрлек һәм киңрәк, гомумкешелек кыйммәтенә ия булырлык асыл мәгънәсе нәкъ менә шул икенче катлам белән бәйле иде. Мәгълүм ки, совет заманында рәсми идеологиягә йөз тоткан әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәне әдәби иҗатның әнә шул өске катламы белән күбрәк кызыксынды, икенче катлам исә игътибардан читтәрәк калды. Хәзер совет чоры әдәбиятын яңача өйрәнү һәм укыту да, моңа кадәрге «ак тап»ларны бетерү белән бергә, ахыр чиктә мәгълүм әсәрләр эчтәлегенең менә шушы икенче

(Ахыры 10 нчы биттә).

Әдәбиятыбызны хәзер ничек өйрәнергә?

(Ахыры. Башы 9 нчы биттә).

катламына игътибарны арттыруга корылырга тиеш. Бу катлам совет чоры әдәбиятыбызны ниһаять милли әдәбият итеп өйрәнүгә дә нигез була ала. Чөнки анда автор белән геройларның ихлас уй-фикерләре, хисләре, гадәтләре, хосусый яшәү рәвешләре һ.б. аша халыкның холык-фигыле, гореф-гадәтләре, омтылыш-хыяллары һәм хәтта язмышы да чагылыш таба.

Әдәбиятны милли сәнгать итеп карауда һәм бәяләүдә аның халык иҗаты белән бәйләнешләрен өйрәнүнең дә әһәмияте зур. Чөнки халык иҗаты — әдәби иҗатның һәм гомумән сәнгатьчә фикерләүнең миллилеген тәэмин итүче мөһим чыганакларның берсе. Гәрчә элеккерәк елларда әдәбиятның халык иҗаты белән бәйләнешләрен өйрәнүгә азмы-күпме дикъкать ителсә дә, соңгысының әле искә алынган вазифасын ачыклауга әллә ни игътибар булмады. Хәзер исә әлеге бәйләнешләрне өйрәнгәндә халык иҗатыннан файдалануның нәкъ менә сәнгатьчә фикерләүдә миллилекне саклауга һәм үстерүгә хезмәт итүен күрсәтүгә дикъкатьне көчәйтергә кирәк. Фольклорның мондый функциясе дә әдәби иҗатның әлеге дә баягы икенче катламында «яшерелгән» иде. Кыскасы, совет чорындагы әсәрләрнең реаль кыйммәте дә нигездә менә шул катламнан чыгып билгеләнергә тиеш.

Бу дәвердәге әсәрләрне аңлатуда һәм бәяләүдә кайчак тагын бер нәрсәгә игътибар итү кирәклеге сизелә. Эш шунда: совет заманында язылган әсәрләрдә кайвакыт дөнья әдәбиятында күптәннән күзәтелә торган бер тенденция үзен сиздерә. Мәгълүм ки, дөнья әдәбиятының кайбер күренекле вәкилләре конкрет иҗтимагый-сәяси карашлары белән художниклык фикерләве тәңгәл килмәве, бәлки соңгысының тирәнрәк һәм киңрәк булуы белән характерланалар. Бу төр әдипләргә мисал итеп еш кына Бальзак, Стендаль, Достоевский яки Л.Толстойларны китерәләр. Алар үз әсәрләрендә кайчак художник буларак шәхси иҗтимагый-сәяси карашларына тәңгәл килмәгән һәм хәтта аларны инкарь иткән фикерләр чагылдыралар. Мондый күренеш безнең кайбер әдипләребез иҗатында да үзен сиздерә. Мисал өчен Г.Ибраһимов белән Һ.Такташның совет чоры иҗатында кайвакыт автор әйтергә теләгән белән аның әсәрендә тәгаен әйтелгән арасында тәңгәллек булмавын яисә берсе икенчесен кире кагуын очратырга мөмкин. Менә бу үзенчәлеккә игътибар итү дә аларның иҗатын хәзер башкачарак, ягъни киңрәк бәяләргә мөмкинлек бирәчәк.

Совет чоры әдәбиятын өйрәнүгә тарихи-милли яссылыкта килү мираска, традицияләргә мөнәсәбәт кебек моңа кадәр рәтләп өйрәнелмәгән, әмма милли әдәбиятның яшәве өчен бик мөһим мәсьәләне объектив яктыртуга киң юл ача. Мәгълүм ки, моңарчы совет заманы әдәбиятын, яңа тип әдәбият рәвешендә каралуы сәбәпле; үткәндәге әдәби мирас белән алыш-биреше бик чамалы булган яки бөтенләй буш җирдә барлыкка килгән дип фараз кылу шактый таралган иде. Ә менә хәзер, мәсьәләгә җентекләбрәк карый башлагач, әлеге фаразның берьяклырак һәм хәтта ясалмарак та икәнен танырга туры килә. Мисал өчен гражданнар сугышы елларында, большевикларның әдәбият дөньясы белән җитәкчелекне үз кулларына алып өлгермәүләре аркасындадыр, ахры, мирас әле гомумән актив кулланышта иде, хәтта ул чорның мәдәни-рухи тормышында нигез ролен дә уйнады дияргә мөмкин. Аерым фактларга килсәк, 1918 елда совет властен кабул итә алмыйча чит илгә мөһаҗирлеккә киткән Г.Исхакый әсәрләренең соңгы 8 нче томы дөнья күрә. Шул ук гражданнар сугышы елларында Г.Ибраһимовның революциягә кадәр язылган «Безнең көннәр» романы (беренче вариант, 1919), «Табигать балалары» (1919), «Караңгы төннәрдә» (1920), «Картлык көннәрендә» (1920), «Көтүче карт» (1921) кебек хикәя җыентыклары һәм хикәяләре аерым китап булып басыла. Шушы ук вакытта әле тагын күп кенә язучыларның революциягә кадәр иҗат ителгән әсәрләре дөнья күрә. Аннан соң әлеге елларда үткәндәге әдәбиятның кайбер традицияләре, бигрәк тә романтизм яки нәсер жанры икенче сулыш алалар дияргә мөмкин.

Гражданнар сугышы илдә урнаштырылып килүче яңа системаның җиңүе белән тәмамлангач, бу җиңү белән рухланган һәм гайрәтләнгән яңа хакимият тормышның бөтен өлкәләрдә үзен хуҗа итеп сизә һәм ныклап үз сәясәтен үткәрә башлады. Шул нигездә әдәбият өлкәсендә дә партия җитәкчелеге көчәйгәннән-көчәя барды. Бөтен сәнгать кебек, аның ул вакытта бигрәк тә әһәмиятле бу төре дә шушы яңа хакимияткә хезмәт итәргә, аның агитаторы, пропагандисты вазифасын башкарырга тиеш иде. Совет системасы, үзен башка иҗтимагый системалардан аерып, дөресрәге, алардан өстен куюы сәбәпле, үзенең яңа әдәбият-сәнгатен дә булдыру максатын алга сөрде. Табигый, бу әдәбият-сәнгать башка җәмгыятьләрнекеннән нык аерылырга, хәтта кайчак алар белән алыш-биреше дә булмаска тиеш дип фараз кылынды. Совет әдәбиятының да шундый радикаль яңалыгын максат итеп куеп, большевистик пропаганда баштарак, бигрәк тә 20 елларда, үткән мираска шактый кире, пролеткультчылык карашларында торды дияргә мөмкин. Нәтиҗәдә әдәби мираска нигилистик мөнәсәбәт бу елларда матбугат битләрендә, әдәбиятка караган кайбер рәсми документларда киң чагылды. Бу мөнәсәбәт әдәбиятның үзендә дә сизелми калмады, әлбәттә. Анда да, үткәндәге традицияләрне искергән дип табып, һәртөрле ясалма «экспериментлар», «шаккатыризмнар» белән мавыгып алу булды.

Шулай да, гомумән алганда, әдәби иҗатның үткәннәр тәҗрибәсе белән бәйләнешләре һич тә өзелмәде. Киресенчә, ул тәҗрибә аның өчен бик уңайсыз яңа иҗтимагый-идеологик шартларда да әдәби дөньяда ныклы урын алды, әйтергә мөмкин, эстетик нигез булып торды. Бу хәл күпмедер дәрәҗәдә үткәндәге әдәби тәҗрибәбезнең яңа идеология корган чик корылмаларын үтеп чыгарлык көче һәм җегәре булу белән бәйләнгәндер, ахры. Әлеге тәҗрибә совет чорында әдәбиятыбызның күбрәк икенче, эчке катламында яшәвен дәвам итте. Аңа таянучы күренекле әдипләр яңа чор әдәбиятында хәтта үз мәктәпләрен тудырдылар. Мисал өчен 20-30 елларда халык шагыйре Тукайга беркадәр нигилистик карашлар чагылып китсә дә, аның бу дәвер татар поэзиясенә йогынтысы бервакытта да тукталмады, киресенчә, аны үзләренең остазы итеп таныган шагыйрьләрнең саны арттканнан-арта гына барды. 1917 елдан соңгы әдәбиятыбыздагы тагын бер мәктәп Г.Ибраһимов исеме белән бәйләнгән. Инде әйтелгәнчә, революциянең беренче елларыннан ук яшь язучыларга көчле йогынты ясаган бу әдип, репрессиягә эләгүе аркасында, 40-50 елларда онытылуга дучар ителеп торса да, аның тәҗрибәсе әдәбиятта яшәвен дәвам итте. Тукай белән Ибраһимовның мондый йогынтысы, әдәбиятның эчке катламында «яшеренгән» булуы аркасында һәм кайчак бездәге идеология рухына туры килеп бетмәве сәбәпле, моңа кадәр өстән-өстән генә билгеләп үтелде, ныклап өйрәнелә алмады. Димәк, хәзер фәнни тикшеренүләрдә әдәбиятта традицияләрнең ролен яктыртканда да әлеге дә баягы икенче катламга игътибарны арттырырга кирәк.

Әдәбият тарихыбызның совет чоры фәнни яңартып өйрәнүдә һәм бәяләүдә моңа кадәр онытылуга дучар итеп киленгән әдәби фактларны яки күренешләрне кире кайтару тагын бер мөһим фактор булып тора. Алдарак М.Гафуриның «Татар байрагы» шигыре белән Ф.Әмирханның «Март каһарманы» хикәясен торгызуның гына да нинди зур фәнни әһәмияткә ия булуын күрдек. Тагын, мисал өчен, 1921 елгы ачлыкка багышланган әсәрләргә, аерым алганда, М.Гафуриның «Кеше ашаучылар» поэмасына һәм Г.Ибраһимовның «Адәмнәр» повестена, шулай ук Ф.Әмирханның «Шәфигулла агай» повесте белән «Тәгъзия» хикәясенә, Г.Рәхимнең «Идел» повестена һ.б. яңача бәя бирү 20 еллар татар әдәбиятын төрле яклап баетып җибәрергә булышачак. Эш менә нәрсәдә. Моңа кадәр совет чоры әдәбиятын без, хаким идеология таләпләренә буйсынып яки ияреп, башлыча бер яссылыкта, ягъни аны илдә яңа тормыш төзү һәм яңа кеше тәрбияләү өчен көрәшүче, шушы тормыш белән кешегә дан җырлаучы итеп кенә күреп һәм күрсәтеп килдек. Әле генә искә алынган әсәрләр исә бу дәвер әдәбиятыбызга, аерым алганда, аның 20 елларына мондый берьяклырак караштан арынырга, аны тулырак һәм күптөслерәк итеп яктыртуга булышачаклар. Әйтик, совет пропагандасы, бездәге системаны дөньядагы иң алга киткән, иң прогрессив, гадел һ.б. система итеп күтәреп, анда ниндидер социаль фаҗигаләр була алуы ихтималын ук кире какты. Шунлыктан әдәбиятта моңа бераз гына ишарә ясау да совет чынбарлыгын бозып күрсәтү дип бәяләнде. 1921 елгы ачлык турындагы әсәрләр дә үз вакытында менә шундый бәя белән кире кагылдылар. Әлеге әсәрләргә хәзер объектив бәя бирү совет заманында да бездә социаль фаҗигагә урын булуын һәм аларның үз чорында ук татар әдәбиятында да күпмедер чагылыш табуларын раслауга хезмәт итәчәк. Әсәрләрдә табигать афәте генә булып калмаган, бәлки ул вакытта совет властеның крестьяннарны талау сәясәте белән дә бәйләнгән әлеге ачлык фаҗигасенең милли төсмер алуын да сиземләргә мөмкин. Чөнки аларда бу ачлыкның татар халкына зур югалтулар китерүенә дә ишарә ясала. Алдарак искә алган әсәрләр әдәбиятыбызны эстетик яктан да баеталар. Моңа кадәр совет чоры әдәбиятын яңа системага дан җырлаучы итеп кенә карау аның поэтикасын да тарайтып һәм бертөслерәк итеп күрсәтүгә китерә иде. Ягъни анда яңа тормышны сурәтләүдә якты төсләр генә кулланылган икән дигән тәэсир кала иде. Югарыда телгә алган әсәрләр исә совет чоры әдәбиятыбызның мәгънәви яктан гына түгел, поэтик планда да баерак һәм күптөслерәк булганын күрсәтәләр.

1917 елдан соңгы татар әдәбияты тарихын һәм теориясен яңартып өйрәнүгә тагын да зуррак өлешне мөһаҗирлектә яшәгән әдипләребез иҗаты кертә ала. Алар арасында беренче чиратта Г.Исхакый мирасы игътибарны җәлеп итә. Бу мирас белән әле яңа гына таныша башлау да аның, барыннан да элек, әлеге дәвер әдәбиятыбызны милли әдәбият итеп өйрәнүдә зур методологик әһәмияткә ия булуын күрсәтә. Чөнки ул «Милли әдәбиятның асылы нидән гыйбарәт? Аны нинди методологик нигездә өйрәнергә кирәк?» кебек үзәк, концептуаль сорауларга ачык җавап бирә. Моннан тыш Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге күптармаклы иҗатының хәзергә безгә билгеле өлеше дә бу мирасны фәнни әйләнешкә кертүнең әдәбиятыбыз тарихын яктыртуда теоретик характердагы җитди генә үзгәрешләр тудырачагын искәртә. Мисал өчен аның мирасы әдәбият тарихын чорларга бүлү, анда идея-эстетик күчемлелек, традиция һәм яңалык, иҗат методы, шәхес концепциясе, заман герое, жанр һәм стиль, әдәби бәйләнешләр, милли һәм гомумкешелек кыйммәтләренең үзара мөнәсәбәтләре һ.б. мөһим мәсьәләләрне яктырту өчен яңа кызыклы җирлек бирәчәк. Ахыр чиктә бу мирас әдәбиятыбыз тарихын халык тарихы һәм язмышы белән тыгызрак бәйләп карау кирәклегенә инандырачак.

Башта мин бу мәкаләне язуга совет чоры әдәбиятыбызны, бигрәк тә аның әүвәлге елларын, фәнни яңартып өйрәнүгә матбугатта чагылган аерым бәхәсле карашлар йогынтысында һәм шуларга җавап бирү нияте белән алынуымны әйткән идем. Әмма алга таба әлеге дәвер әдәбиятын шулай өйрәнү мәсьәләсенә киң әдәби-фәнни җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтү теләге дә туды. Чөнки бу эш тар даирә галим-голәмага гына түгел, бәлки киң катлау укучылар өчен, аларны заманыбыз таләп иткән милли рухта тәрбияләү өчен дә кирәк. Шул ук вакытта элекке СССРдагы кайбер милли әдәбият фәннәрендә инде ныклап һәм җитди рәвештә көн тәртибенә куелган әлеге мөһим мәсьәлә буенча безнең матбугат битләрендә зур бер сөйләшү үткәрү кирәклеген аңлау да этәрде мине бу чыгышка. Шушы бик кирәкле эшкә «Мәдәни җомга» алыныр, бәлки?

***РЕДАКЦИЯДӘН.** Чыннан да, безнең белән даими язышып торучы күренекле галимебез киң мәдәни җәмәгатьчелектә уртага салып сөйләшүне таләп иткән гаять әһәмиятле мәсьәлә күтәрә. Әгәр без, китапның изгелек дәрәҗәсенә күтәргән кавем, «әдәбият» сүзендә «әдәп» мәгънәсен дә күрергә күнеккәнбез икән, әдәбиятның тәрбия өлкәсендәге биниһая зур көчен, гомумән, халык язмышында бәһаләп бетергесез олы миссиясен мөмкин кадәр тулырак аңлап эш итәргә бурычлыбыз. Әдәбият галимнәре, язучылар, мәгариф хезмәткәрләре, китап сөючеләр! Шушы мәсьәлә уңаеннан сезне зур сөйләшүгә чакырабыз. Фикер алышуны инде якынлашып килүче 1996 ел башыннан газетада яктыртып барырга уйлыйбыз. Әйдәгез, күтәрелгән мәсьәлә буенча күпмедер дәрәҗәдә уртак фикергә килү өчен каләмнәребезне уйнатып алыйк әле.*

Заһид МӘХМҮДИ

МУНЧА

Ике пәрдәле трагимәзәк

КАТНАШАЛАР:

Җәмил — пенсиядәге карт, 66 яшьтә
Мәчтүрә — аның хатыны
Ленин
Иблис

(Ахыры. Башы 21 нче санда).

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мунча эче күренеше. Түрдә самогон аппараты, аның өстендә Ленин портреты эленеп тора. Ләүкә урта тирәдәрәк. Түшәмгә кәрәчин лампасы эленгән.

Иблис, аның артыннан мылтык тоткан Җәмил килеп керәләр.

Җәмил (*мылтык түтәсе белән Иблисне этә*). Әйдә, атла! (*Мунчада үзләреннән башка беркем дә юклыгын күреп*). Иптәш Ленин! Анысы кая китте инде тагын?

Иблис. Кыяфәтең бик куркыныч иде бит, чыгып качкандыр. (*Авызын мыскыллы кыйшайтып*) Революция-ә, Ленин, имеш! Революцияне аны бөтен авылны аякка бастырып ясамыйлар. Шыпырткына эшләнә андый эшләр. Синең кебек сертотмас үрдәк белән нинди революция ясап булсын!

Җәмил (*Иблиснең артына тибә*). Тавышыңны күтәрмә, йонлы колак! Син лутчы ләүкә астын кара!

Иблис иелеп ләүкә астын карый.

Иблис (*ачу белән*). И тинтәк, Ленин кадәр Ленин ләүкә астында качып ятамы?

Җәмил (*мылтык белән яный*). Утыр, тегесен булса да котәрбез.

Иблис. Кемне? Әлмиевнеме? Белмим, малай, трибунал кадәр трибунал сыеп бетә алмас бу хәерче мунчага.

Җәмил. Яхшысын үзең салырсың. (*Кадакта эленеп торган бауны кулына ала*). Диварга карап бас!

Иблис аркасы белән баса. Җәмил җәһәт кенә аның кулларын, аякларын бәйли.

Җәмил. Хәзер ләүкәгә мен инде.

Иблис (*каһкаһә белән*). Чабындырмакчы буласың мәллә?

Җәмил. Телеңә салынма, мен диләр сиңа!

Иблис. Очыпмы?

Җәмил аңа ләүкәгә менәргә булыша. Аннары үзе мич каршындагы сәкегә утырып махра кабыза.

Иблис (*еламсырап*). Китер әйдә трибуналыңны! Мин барыбер «Яшәсен революция!» дип кычкырып үләчәкмен. (*Бар тавышына акыра*). Яшәсен революция-ә!

Җәмил. Акырма шулай, базар каргасы!

Иблис (*мышкылдап*). Әллә җибәрәсең генәме, ә? Тәмугта бик юксынганнардыр инде мине. Теләсәң, сине үзем белән алам. Урынбасарым булырсың. Ятарсың шунда типтереп. Иң дилбәр хур кызларын бирермен. Бу дөньяда нинди рәхәтлек күрдең әле син?

Җәмил (*авыр сулап*). Рәхәтлек күреп булмады инде, анысы хак.

Иблис (*ләүкәгә сузылып ята*). Ыскучны монда, агайне. Ашарга бирмәдең, хөмереңне кызгандың, хет гармуныңны уйнап җибәр инде. Җырлат бер рәхәтләнеп, үләр алдыннан!

Җәмил. Гармун үзебездә, анысы җөлке түгел. (*Торып ләүкә астыннан гармунын тартып чыгара*). Нинди җыр җырлыйсың килә?

Иблис. «Алмагач»ларны җиффәрт әйдә!

Алмагачта була, диләр,
Сандугачлар оясы;
Җир шарында нурлар сибә
Коммунизм кояшы.

(*Җырлаудан туктый*). Их, барыбер ыскучны...

Җәмил. Шыңшып ятма анда, әбиеңдә кунакта түгелсеңдер. (*Моңлы гына бер көй сыздырып җибәрә*).

Иблис. Нигә шулай бик моңсу бу дөнья, ә? (*Җәмилгә*). Сөйләп җибәр әле үзең турында. Син бик күпне күргән кеше бугай. Төрмәдә нигә утырдың соң?

Җәмил. Ә син каян беләсең минем төрмәдә утырганны?

Иблис. Хатының белән сөйләшкәндә үзең әйттең ич. Сөйлә, бераз җиңелрәк булып китәр. Кайда тудың, кайда үстең?

Җәмил. Нәрсәсен сөйлисең инде аның. (*Гармунын куеп, махра кабыза*) Егерме тугызда тудым. Гаиләдә җиденче бала идем. Әти, мәрхүм, бик яшьли үлеп китте. Ярым ялангач, ярым ач булып үстек. Чабата да юк иде аякка кияргә Кырык беренче елны сугыш башланды. Өч абыемны да берьюлы фронтка алдылар. Кырык икедә үземне дә ФЗУга димләп килделәр. Ул вакытта синнән сорап тормыйлар иде бит, көчләп алып китәләр иде. Качтым Өч көн Шода урманнарында адашып йөрдем. Качасы булган шунда берәр шәһәр җиренә. Юк шул, әни сагындырды, кире кайттым, юләр Шул ук көнне йортыбыз каршына тузаннар туздырып тарантас җигелгән ат килеп туктады Авыл советы Фәиза белән комсомол Рәхим мине алырга килгәннәр икән. Тарантаска бәйләп ташладылар да туп-туры Казанга! ФЗУдан да качтым. Һаман әнкәй сагындыра иде. Кая, уноч яшьлек сабый гына бит әле ул чакта: Арчага кадәр кайтып җиттем җитүен. Анда тагын эләктерделәр. Аннары инде калуния тормышы башланды. Төрле балалар бар иде арада, әшәкесе дә, яхшысы да, дигәндәй. Менә шуннан соң инде барысы да чуртыма тәгәрәде. Аннан чыккач, домушниклар белән бәйләнеп киттем Бер төндә алты кибет бастык, малай. Җиденчесендә эләктерделәр. Шуннан бирле гел зәңгәр тәрәзәле туган йортым, әнием кәрә төшкә.

Иблис (*күз яшьләрен сөртә*). Җә, эләктерделәр, шуннан?

Җәмил. Төрмәдән чыккач авылга кайттым. Әни дөньяда юк, сеңелләрем дә, кияүгә чыгып, кайсы кая таралышып беткән. Сугышка киткән абыйларым исән-сау әйләнеп кайта алмадылар.

Иблис. Теге Фәизаны очратмадыңмы соң?

Җәмил. Аны сугыштан кайткан абыйсы, бик каты кыйнап, кычыткан арасына ыргыткан, дип сөйләделәр. Шуннан соң төнлә авылдан чыгып сызган ул. Үзеннән егерме яшькә кече теге комсомол башлыгы белән инде. Бик кабахәт нәрсә иде, бөтен авылның канын эчеп яшәде. Басудан кайтканда хатын-кызларның ыштаннарына кадәр тикшерә иде. Җиде балалы Хәлимә апаны бер уч борчак өчен биш елга төрмәгә утырттырды, мөртәт. Кире кайта алмады Хәлимә апа, шунда үлеп калды. Район үзәгеннән килгән бөтен налуг инспекторлары гел шул Фәиза өендә куныл яталар иде. Төнлә урамга чыксаң, аның чыкылдаганы гына ишетелә.

Иблис. Исәнме әле ул?

Җәмил. Талак булсынмыни аңа! Казанда яши хәзер. Балалары юк. Ире үлгән. Дөрес булса, Фәизасы хәзер мәчеттә абыстай булып йөри, ди. (*Көрсенеп*). Менә шундый, шундый хәлләр.

Иблис. Үзең турында да сөйләп бетер инде.

Җәмил. Ә нәрсә сөйләргә? Авылда каласы килмәде. Туган нигез корыган, Мәчтүрә һаман Кәбирен көтә, әни дә юк. Киттем Воркута якларына Пенсиягә кадәр шахталарда эшләдем Уемда туган авыл да, Мәчтүрә генә иде. Бервакыт, ни булса да шул булыр дип, аңа хат яздым Озак көттермәде, җавап хаты җибәрде Бергә яшәргә риза, дигән. Ул чакта инде дөнья шактый бутала башлаган иде Фатирымны гашпап кайтып китәргә туры килде Себер ягы бит, алыштырып булмады Гомерем буе бөртекләп җыйган ничәмә-ничә мең сум акчам да кычкырып янды кассада Авылга кайткач, нарат бүрәнәләрдән зур йорт салырмын, Мәчтүрә белән бәхетле генә гомер кичерербез, алма бакчасы утыртырбыз, умартачылык белән шөгыльләнермен, дип хыялланган идем, юләр. Хәзер бернәрсәгә дә күңел үсми. Бердәнбер юанычым шул урыс өчесендә генә.

Иблис. Төкер барысына да. (*Өскә ымлап*). Теге нәрсә дигән үзенең хәдисләрендә? Байлыкка табынма, кош кебек яшә, аягыңны сузган чакта бернәрсәне дә үзең белән алып китә алмассың, дигән.

Кинәт ишектә Ленин күренә. Җәмил җәһәт кенә сикереп тора да, мылтыкны кулына алып, үрә ката.

Ленин. Исәнмесез, иптәш... (*Җәмилгә сораулы караш ташлый*).

Җәмил. Хәйбуллин булам мин.

Ленин (*кул бирә*). Бик шат. Тамагыгыз тукмы?

Җәмил. Ие. Әмрикәнский ботка ашадык, иптәш Ленин.

Ленин. Яхшы. Бу юлы без, властьне кулга алгач, башка юлдан китәрбез, иптәш Хәйбуллин.

Җәмил (*күзләрен акайта*). Нинди юлдан?

Ленин. Урта Азия аша туп-туры Һиндстанга.

Җәмил. Анда ни эшлибез?

Иблис (*сүзгә кушыла*). Нәрсә булсын, Һинд океанында итекләрне юарбыз.

Ленин (*Иблискә*). Бик дөрес, иптәш! Революцион үзаң безгә бик кирәк.

Җәмил. Монда гына юып булмыймы соң аны?

Ленин. Борчылма, монда да юарбыз әле, иптәш. (*Куеныннан кесә сәгатен чыгарып карый*). Аһ, соңга калам икән, Надюша чәй куйган иде.

Чыгып китә.

Җәмил (*аның артыннан ук ишектән башын тыга*). Иптәш Ленин!

Ленин тавышы. Нәрсә тагын?

Җәмил. Ә иптәш Әлмиев кайда?

Тавыш. Ул нәрсәгә кирәк?

Җәмил (*кулы белән ләүкәгә ишарәли*). Әнә теге тәмуг чәчәге трибунал көтеп ята иде.

Тавыш. Килегез әле бирегә.

Җәмил чыгып китә. Ленин белән пышылдашып алгач, яңадан керә.

Иблис. Нәрсә диде?

Җәмил (*уңайсызланып*). Теге, ни диде...

Иблис. Нәрсә соң ул теге ни?

Җәмил. Атарга кушмады кушуын.

Иблис (*авызын ера*). Менә, күрдеңме?

Җәмил. Асарга кушты ул сине. Патрунынңны иканумияләп, бау белән генә маташ, диде.

Иблис (*акыра*). Үтерәлә-әр!

Җәмил. Акырма, анаңны саткан нәрсә! Үтерергә җыенган кеше юк бит әле сине!

Иблис. Җәзаларга җыенасың, ызначит? Яшәсен революция-ә!

Җәмил (*мылтык түтәсе белән кизәнә*) Әнәк эте сыман шыңшып ятма Монда синнән башка да ми кайный (*Ишек тупсасына утырып, узалдына*). Ошамый әле бу миңа. Һиндстанга кадәр барып итек юып йөрергә тинтәк түгел ич мин. Ну ахмак та икән бу Ленин!

Иблис. Унҗиденче елдагысы мондый ук ахмак түгел иде. Ә бусы шыр тиле. Кичә телевизордан чыгыш ясаган иде. «Если я стану президентом, в каждой семье будет стоять шампанское, — ди. — Я интернационалист. Исянмесез, иптяшляр! Вот видите, я даже говорить умею по татарский, — ди. — Всех татар отправлю в Монголию. Там сифилис, там грязь», — ди.

Җәмил. Шулаймы?

Иблис (*авызын мыскыллы кыйшайта*) Шулай шу-ул!

Җәмил. Нигә аны алдарак әйтмәдең?

Иблис (*үзенең ияк астына чиертә*). Исерек идем бит. Әле дә баш чатный. Салып бирче бераз, ә?

Җәмил Иблискә шешә авызыннан гына аракы эчертә. Теге, чыраен сытып, аның телогрейкасын исни.

Иблис. Чишәсеңме бауны, юкмы?

Җәмил (*мылтыкны дивардагы кадакка элә*). Чишәм, чишәм. (*Иблиснең кулларын, аякларын чишә*).

Иблис (*беләкләрен уа*). Быр-р, суы-ык. (*Ләүкәдән төшеп, биергә, сикерергә тотына*).

Җәмил. Күңелле яшисең, моңаймыйсың бер дә.

Иблис. Ә нигә моңаерга? Типтереп яшибез әле, исән булсак! Тагын салып бир әле!

Җәмил (*кәҗә тоягы күрсәтә*). Менә сиңа!

Иблис, җаен туры китереп, аның өстенә менеп атлана.

Иблис. Әһә, эләктеңме! Хәзер барысы да мин әйткәнчә булачак.

Җәмил. Кая, төш әле өстән. Бу тиләләр илендә синнән башка да җилкәдә утыручылар күп.

Иблис. Хәзер бер мин генә утырырмын инде.

Җәмил. Аһ, арт сабагыңны укытыйм әле! (*Тормакчы була, ләкин тора алмый*). Әй, син! Кайчанга тикле утырмакчы буласың анда?

Иблис. Кыямәт көненә кадәр. Аннары күз күрер.

Җәмил. Озаккарак китә икән шул... Кара, син бит мине әле урынбасарың итмәкче идең.

Иблис. Итмәкче идем дә, киресен уйладым хәзер. Урынбасарларым болай да җитәрлек минем. (*Бармакларын бөкләп саный*). Сталин, Берия, Вышинский, Ягода... Күп инде, күп, санарга бик озак.

Җәмил. Шәп кадрлар сайлагансың. Эш тә калмагандыр үзеңә?

Иблис. Эш җитәрлек. Якты дөньяга чыгып адәм затларын юлдан яздыру белән шөгыльләнәм мин. Күптән түгел менә КПСС тарихын өйрәнә башладым. Алдынгы тәҗрибәсез булмый, агайне. Сез мине дә уздырып җибәргәнсез кайбер гамәлләрегез белән. Прәме көнләшеп үләрлек! Рәсәй телевидениесен карау да бик нык ярдәм итә. Алдау дигәндә, алардан да маһир кеше юк.

Лампа сүнә. Мунча эчен караңгылык баса.

(Ахыры 12 нче биттә).

(Ахыры).

Иблис. Син нәрсә. юри сүндердеңме утны? *(Галибанә тавыш белән)* Кабыз хәзер үк!

Җәмил. Акырма. хәзер көрәчин салам

Җәмил. караңгыда капшана-сукрана лампага керәчин сала Кабыза Иблис күренми Кием ме ич алдында аунап ята

Җәмил *(аның киемен сөке астына тыга)* Әй. кайда син?

Иблис. Кайда булсын. синең өстеңдә атланып утырам.

Җәмил. Шыттырма. *(Кытыгы килеп көлә башлый)* Кытыклама инде шул кадәр. үтерәсең бит! Җә, җә. җитте сиңа!

Тавыш. Ышандыңмы инде хәзер?

Җәмил. Ышандым, бик ышандым. Иннокентий. Карале. нигә туныңны салып ташладың әле син? Эссе булып китте мәллә?

Иблис. Размеры туры килми башлады. Мин бит хәзер орчык кадәр генә.

Җәмил. Ә-ә, алай икә-ән. кыямәт көнгә тикле аягыңны суза күрмә инде. бездә кышлар бик салкын була.

Иблис. Аһ син. ахмак адәм заты мине мыскыл итәргә батырчылык итәсеңме?! Менә сиңа! Менә сиңа!

Җәмил *(маңгаен тота).* Ай, сукма шулкадәр. үтерәсең бит!

Тавыш. Ошамыймы? Менә сиңа! Менә!

Җәмил. Каравы-ыл! Үтерәлә-әр!

Иблис. Кара аны, бөтен тынының чыгарасы булма!

Җәмил. Чыгармам. чыгармам, Иннокентий. *(Еламсырый).* Житмеш ел өйрәттеләр бит инде. Тел ачыла башлагач кына. син килеп чыктың *(Янә маңгаен тота).* Уй! Бетте. бетте. авызыма су каптым!

Иблис. Кыскартырбыз әле без сезнең телегезне! Хак сүз әйтә телеләш Монголиядә черетергә кирәк сезне! Иртәгә үк бер почмакка икуна асып куй! Аннары сине чиркәүгә алып барып чукындырырбыз Син Женя. хатының Матрена булыр.

Җәмил. Син бог белән дус түгел бит.

Иблис. Дус булмаса соң. аның каравы син дә төре белән дус түгел.

Җәмил *(Ленин портретына ымлый)* Әнә тегендә берәү тора ич инде шул житмәгәнмени?

Тавыш. Ярый житеп торыр. ахрысы көндердең

Әтәч кычкыра

Тавыш. У у. норсыз! Сөймим шул әтәч тавышын! *(Җәмилгә)* Бар әкәмәтләп кер тизрәк!

Җәмил *(елак тавыш белән)* Бердәнбер әтәчемне дә күпсенмә инде син Мин бит синең тәмугыңа барып хуҗа булып йөрмим.

Тавыш. Әллә хуҗа булыр идеңме? Чабата кайтарып торма кушканны үтә! Юкса ..

Җәмил *(буйсынып).* Киттем. киттем

Тавыш. Тиз генә үтермә җәберлә бераз!

Җәмил чыгып китә Тынлык Бераздан тузынып әтәч кыткылдаганы һәм Иблиснең «Үтерәлә әр!» — дип чыелдаган тавышы ишетелә

Ниһаять ике кулы белән йөзен каплап үкерә үкерә Иблис атылып керә Күтендә тезенә кадәр төшеп торган чәчәкле трусик.

Иблис *(ләүкәгә йөзтүбән каплана)* У у афә әт! Чак кына күзсез калдырмады ы У у гомерең буе тавык күрмәгән нәрсә ә!

Җәмил керә Кулында Иблиснең мөгезе

Җәмил *(аның янтыгына төртә)* Мә бүтен ташлап калдырма бу нәрсәңне

Иблис *(аңа игътибар итмичә).* У-у, банди-ит! У-у-у...

Җәмил сәкегә барып утыра, кулына гармунын ала.

Җәмил. Җә. үкермә шулкадәр, мунчаны агызып җибәрәсең бит! Миндә бер диген келәй бар, ябыштырырбыз.

Иблис *(торып утыра).* Ябыштыр инде син, туган. ябыштыр.

Җәмил. Тамбов бүресе туган сиңа. вәт! *(Җырлый.)*

Әтәч менгән киртәгә

Армиягә китәргә...

Иблис. Зинһар җырлама бу җырны! Әтәч диген сүзне ишетсәм. кан басымым күтәрелә башлый! *(Калтырана.)* Быр-р-р...

Җәмил. Өстеңә ки тизрәк, аңгыра сарык. өшеп үләсең ич инде.

Иблис ләүкәдән төшеп киенә

Заһид МӘХМҮДИ

МУНЧА

Ике пәрдәле трагимәзәк

башлый.

Җәмил *(йодрык күрсәтә).* Тагын да шаярырга уйласаң, беттең дип уйла. Иманыңны алырмын!

Иблис *(читкә тайпыла).* Чү, чү! Иманлы адәм буларак, син мине тәрбияләргә генә тиеш. *(Ләүкәгә барып утыра.)* Хәер, барыбер файдасы булмаячак. *(Моңаеп.)* Иблис бит мин. Әнкәй, мескен, миннән тумас борын ук ваз кичкән, диләр. *(Елый.)*

Җәмил. Болай бик нечкә күңелле дә кебек инде үзең.

Иблис *(явызланып).* Кем, минме нечкә күңелле? Бик беләсең килсә, өшәкелек эшләмичә торсам минем бөтен йокым кача. Узган ай әнә бер сукырны юл аркылы чыгарып куйгач, трамвай юлына бәкләп салмаганлыгыма үкенеп. чүт инфаркт алмадым.

Җәмил. Хулиган син. Эчеңә җыен өшәкелекне җыйгансың.

Иблис *(авызын ера).* Менә шунда шул бөтен хикмәт. Төннең ниндн булуын белмичә, көнне күз алдына китереп булмаган кебек, өшәкелектән башка яхшылыкның да нәрсә икәнлеген күз алдына китереп булмый. Шулай итеп, бу җиһанда аз гына бозыклык та кирәк.

Җәмил *(авызын зур итеп ачып иснәнеп куя)* Ярый, син тәмугыңа кайтып кит. ә мин бераз черем итеп алыйм. Сәгать алтыда фермага барасы бар *(Гармунын сәке астына тыгып. сәкегә сузылып ята).*

Иблис *(мескен тавыш белән).* Ә мөгезне кем ябыштыра?

Җәмил. Телең белән ябыштыр, бик шеп ябыша, диләр.

Иблис сынган мөгезен теле белән ялый-ялый ябыштырырга азаплана, ләкин берни дә барып чыкмый. Җәмил аны күз чите белән генә күзәтеп ята.

Иблис *(өметен өзеп, мөгез кисәкләрен идәнгә томыра).* Ябышмый, каһәр!

Җәмил *(кычкырып көлеп җибәрә).* И, тәмуг сарыгы, тел белән әйбер ябыштырганнарын кайда күргәнең бар?!

Иблис. Соң, үзең әйттең ич.

Җәмил. Ә мин нәрсә әйтмәм. Келәй белән ябыштыралар аны, ахмак!

Иблис. Алайса чыгар келәеңне!

Җәмил. Чыгармыйм әле менә. Бар, үз юлыңда бул. Минем йокым килә.

Иблис. Мөгезсез килеш тәмугка ничек итеп кайтып кермәк кирәк? *(Ачу белән.)* Кайтмыйм, яңа мөгез үсеп чыкканчы шушында утырам.

Җәмил *(авызын ачып иснәнә).* Кайтма, кайтма.

Җәмил гырылдап йокыга китә Иблис, аяк очларына гына басып аның янына килә, колагын куеп, тыңлый. Аның йокыга киткәнлегенә тәмам инангач, ишекне ачып урам якка кычкыра: «Әй, сез, кәмшек танаулар, керегез тизрәк!»

Ишектән иленә инкыйлабка кадәрге телефон аскан бер карт гыйфрит һәм ике яшь җен килеп керә.

Иблис *(галибанә тавыш белән, сәкедә йоклап яткан Җәмилгә күрсәтә).* Бәйләргә!

Төнге кунаклар Җәмилне, авызына чүпрәк тутырып, бәйләп ыргыталар. Теге ыңгыраша, тыпырчына, әмма — файдасыз.

Карт гыйфрит *(еш-еш сулый).* Нишләтергә кушасыз, галиҗанәб?

Иблис. Җәзаларга!

Карт гыйфрит *(гаепле тавыш белән).* Тырнак суыра торган җайланмалар тәмугта калды, галиҗәнап.

Иблис. У-у, булдыксызлар! Алып китегез алайса тизрәк. Тик карагыз аны, иң кечкенә, иң кайнар казанга салыгыз үзен.

Шул мәлне ишектән башына кепка кигән Ленин килеп керә.

Ленин *(күзләрен уа)* Тфү, тфү, бусы нәрсә тагын?

Материя беренчел, аң икенчел. Димәк, алла да юк, иблис тә юк.

Иблис диварга эленгән мылтыкны кулына алып затворны тартып куя.

Иблис *(ачу белән).* Кем, минме юк? Хәзер күрсәтәм мин сиңа үземнең барлыгымны!

Ленин кепкасын салып, кульяулыгы белән тирләгән башын сөртеп куя Маңгаенда — мөгез. Гыйфритләр каушап калып, әле Иблискә, әле аңа карыйлар. Иблис, маңгаен сыпырган булып, мөгезсез булуын күрсәтмәскә тырыша.

Карт гыйфрит *(Ленинның аягын кочаклый).* Кичерегез, галиҗәнап, ялгышканбыз, валлаһи, ялгышканбыз.

Ленин. Ярый, борчылмагыз, иптәш. *(Иблискә бармагы белән күрсәтә).* Ә бу контраны бәйләп хәзер үк ЧКга озатыгыз!

Карт гыйфрит. Тыңлыйм һәм буйсынам, галиҗәнап!

Гыйфритләр Иблискә ташланалар.

Иблис *(каршылык күрсәтә).* Сез нәрсә, хуҗагызны танымый башладыгызмы?

Карт гыйфрит *(Җәмил тарафына ымлый).* Ә бу бәндәне нишләтергә?

Ленин. *(Җәмилне бер кат күздән кичереп, аны аркасыннан сөя).* Афәрин! Менә бусы нәкъ мин әйтеп калдырганча булган. Пролетариат диктатурасыннан башка коммунизм төзү һич мөмкин түгел. *(Җәмилгә.)* Ярый, борчылма, бөтен дөнья буржуазиясен җиңеп чыккач та, туйганчы сөйләшергә өлгерерсең әле. *(Пауза.)*

Тукта, нигә монда шулай бик караңгы? Мин бит сезгә якты киләчәк вәгъдә иткән идем. *(Карт гыйфриткә.)* Кичекмәстән телефон бирегез миңа!

Карт гыйфрит биленә аскан букчадан иске телефон чыгарып аңа тоттыра.

Карт гыйфрит. Рәхим итегез!

Ленин *(трубканы ала).* Мине Кремль белән тоташтырыгыз! Алло!

Тавыш. Әйттем бит инде мин сезгә, йота алган кадәр йотыгыз дип. Артыгын йотып җибәрсәгез, һич борчылмагыз, бер җаен туры китереп костырырбыз. *(Трубканы куя).*

Ленин. Тфү, тфү, шайтан, һичбернәрсә аңламыйм... Алло!..Мине Кремль белән тоташтырыгыз!

Тавыш. Президент тыңлый.

Ленин *(аңламыйча).* Кем дидегез?

Тавыш *(ачулы).* Пре-зи-дент!

Ленин. Ул нинди президент тагын?

Тавыш. Бәйсез Россиянеке!

Ленин. Аны басып алдылармыни? Кемнән бәйсез ул?

Тавыш. Үз-үзеннән.

Ленин. Аңламыйм, берни дә аңламыйм.

Тавыш. Чечня белән эшне бетерик әле, аннары аңлатырбыз.

Ленин. Ярый, шаяртмагыз әле, иптәш. Миңа кичекмәстән Дзержинскийны бирегез! Кемдер миңа мөгез куйган, шуны ачыкларга кирәк.

Тавыш. Мин куйдым аны.

Ленин. Син? Аһ син, сәяси фахишә!

Тавыш. Борчылма, модада бит ул бездә мөгез кую. Сталин үлде, куйдылар! Хрущев үлде — куйдылар! Брежнев үлде — куйдылар! Черненкога да, Горбачка да куйдылар! Үлгәч. миңа да куярлар

Ленин *(трубканы ыргыта)* У ух, контра а! *(Җәмилнең авызыннан чүпрәкне суырып ала)* Сөйләш, иптәш мылтыклы кеше, рәхәтен күр *(Кесә сәгатен чыгарып карый).* Мин киттем, киләсе сайлауларга кадәр! *(Китә)*

Карт гыйфрит *(аны туктата)* Галиҗәнап. нишләтергә соң бу бәндәне?

Ленин. Кулларын чиш тә хатынына тапшыр *(Чыгып киткәндә)* Диктатура алдыннаң демократияле уйнап алырга кирәк .. Товалищи! Социалистическая леволюция о необходимости котолой големили большевики свелшиться!

ПӘРДӘ.

КӨЛСӘҢ — КӨЛ, КӨЛМӘСӘҢ — ЕЛА!

Ләбибә ИХСАНОВА

Базарларга барам әле...

...амвайда шау-шу купты. Кызыл чырайлы, күн ...калы әзмәвердәй егет бер әбинең бүлтәеп ...ан сумкасына кулын тыккан да кире ала ал...на интегә. Сумкага шома гына кергән дә бит, ...а банкадагы акчаны йомарлап тоткач, йод...н чыгара алмыйча азаплануы икән. Әби дә ...ырдап ябышкан сумкасына, егет тә йолкып...олкый. Кешеләр көләләр, кайсылары сүгенә. ...калаша торгач чырт иткән тавыш ишетелде ... әбинең кинәт шиңеп, юкарып калган сум...ннан бала башы хәтле җәрәхәтле йодрык ...ты.

... Карт тәре! Кулы-нишләттең! ... акырды егет, ...ыкка кизәнеп. ...умкасын күкрәгә...ысып тоткан әби ... тынычланып:

- Керереңнән ал...чыгарыңны уйла...нан соң, — диде. ...есә каракларын...җефа чигеп бет... хатыннар акча ... әйберләрен пыя...анкада йөртәләр икән хәзәр.

* * *

...рнең беренче катлары тимергә киенде. ...р ишек, тимер тәрәзә. Ниндиләре генә юк. ...әкләрен күчерел алып җептән челтәр итеп ...лек матурлары да, төрмә тәрәзәсен хәтер...п аркылы-торкылы тимер ябыштырылганна...да җитәрлек. Бары тик мәктәпләр, балалар ...алары һәм әлегә эшләп яткан китапханәләр... тәрәзәләре генә әүвәлгечә ялт итеп тора. ...әкчәдән күрмәкчә, дигәндәй, Шәйхулла ба...да тәрәзәсенә тимер рәшәткә куйдырды. Кор...ы көләләр:

- Ниемә инде ул сиңа? Пенсияңнән башка ...н дә юк бит, — диләр.

...абай мыек астыннан елмая:

- Алыр әйберем бетте, инде карчыгымны ур...чыгарлар дип куркам, — ди.

* * *

...рамвайда ике чибәр кызның сөйләшеп бар...ын тыңлыйм.

- Светка норка шуба алган, паразит. Күрдең... — диде берсе, авызындагы сагызын сабын ...кебек кабарткач кире тартып алганы.

...аның акчасын куры не клюют. Торкиягә ... бит. Бер әйләнеп кайтканчы кәҗә майлары ...а, — ди үзе, заразы.

- Ну и что? За то череп баеды, гад. Давай без ...барабыз. Төрек егетләрен күреп кайтырбыз. ...р бик смазливый була,ди.

...атлы нәселдән булганы күренеп торган көчек ...ып, кызлар янында олы яшьтәге ханым басып ...а иде. Трамвай кинәт тартылып китте дә, әлеге ханым кызлар өстенә ауды.

— Вот анаңны...— дип, кызларның сагыз чәйнәп барганы аны этеп җибәрде — На ногах тора алмагач, өендә сидела бы падла!

— Олы кешегә урын бирер идегез, — дидем, ачуым чыгып.

— Этеме? — диде кызларның икенчесе. Йа, ходай! Киленең шундый булса, нишләрсең?

* * *

Шәһәрне базар басты Трамвай тукталышы саен дип әйтерлек базар Дөү-дөү фургоннар тезелеп киткәннәр дә, анда ни генә сатмыйлар Казанның күн-галантерея фабрикасы фургонында кабарып пешкән ак күмәчләр тезелеп тора

— Ипи сатасызмени?

— Ни эшләмәк кирәк, бер әмәлен тапмыйча булмый бит Өч ай эш хакы алмадык — диде үзе яшь үзе чибәр җитмәсә бик тә ягымлы сатучы кыз

— Ашханәдә пешерәсездер инде?

— Ашханә эшләми Ашарга йөрүче юк Бәләкәй пекарня сатып алган идек шунда пешерәбез

— Хуҗагызның башы эшли икән, кул кушырып утырмаган.

Кайтып барышлый күңелгә бер уй килде әгәр дә мөгәр айлар буе эш хакы алмый утырган журналистлар, китап чыгара алмыйча йөдәгән язучылар берләшеп, әйтик менә, чабата ясау әртиле ачсалар? Әмма дә үтемле товар булыр иде бит Яңа байларның өчәр катлы коттедж интерьерларын бизәргә менә дигән сувенир булыр иде Егылып алырлар иде

* * *

Өч ел инде бу урамда зур гына күлдәвек эссе җәй көнендә дә кипмичә ята Кайдадыр су торбасы тишелгән дә килеп төзәтергә акчамы, кулмы җитми, ди. Җаен тапканнар Су уртасына таш салганнар. Әмма ләкин шул гомер өстеңнән таптап йөрсәләр, таш түгел үзең дә түзмәс идең. Аяк башы орынуга әлеге таш та дер-дер калтырарга тотына икән. Бу сират күперен яшьләр җиңел генә үтә дә бит. карт-корыга ярдәм кирәк. Менә бервакыт күлдәвекнең ике ягына яшь. чибәр кыз белән таякка таянган зыялы карт килеп туктадылар да бер-берсенә карап елмаешып куйдылар.

— Мин сезнең кулыгызны сорыйм. сөйкемле туташ. — диде бабай шаярган атлы булып.

— Машинаң булса, мин риза, бабакай, — дип, урам яңгыратып көлеп җибәрде кыз

Шулай инде безнең халык, көлә-көлә җылый, җылый-җылый көлә..

Камил КАМАЛ

Дусларга киңәш

— Дустым җитәрлек акчам бар
Машина алыйм микән?
Фатирым әйбәт дачам бар
Өйләнеп карыйм микән?
— Нәрсә әйтим? Машина алсаң
Сиңа ике юл кала
Йә — берәрсе сине бәрә
Йә — берәрсе таптала
Әгәр син кеше таптасаң
Ул чакта «беттем» диген
Әгәр сине бәрдерсәләр —
Ике юлың бар синең
Йә оҗмахка эләгәсең
Йә — тәмугка тыгалар
Оҗмахта белем бетәсең
Ә тәмугта юлың бар
Йә синнән кәгазь ясыйлар
Йә сабын кайнаталар
Сабын кайнатсалар — беттең!
Ә кәгазьдә — хутың бар
Кәгазь ике төрле була —
Гәҗит бәдрәф кәгазе
Гәҗиткә эләксән — беттең!
Бәдрәфтә син — кенәз әле
Ирләрнекенә эләксәң
Бетәсеңне беләсең
Инде хатын-кыз кулланса
Бик теләсәң, өйлән соң!

Атаклы Рафаэль

Камал театрында сәхнә рәссамы Рафаэль Шакиров тәрәзә төбендә портсигарын онытып калдырган Истәлекле бу портсигарны табарга өметләнеп театр ишегенә язу элгән «Кто нашел железный портсигар прошу вернуть художнику Рафаэлю» Шул язуны укыган берәү кәгазьгә үз сүзен өстәгән «Замечательный художник Рафаэль умер 300 лет тому назад ..»

Балчык боламыгы

Танылган режиссер Празат Исәнбәт Камал театрыннан гөл төбенә салырга дип бер чиләк балчык күтәреп чыгып килә икән Шунда аңа яшь драматург Зөлфәт очраган

— Кая алып барасың бу балчыкны Празат абый? — дигән

— Ялгышасың энем — дигән режиссер — Бу — балчык түгел ә гөл утыртырга туфрак!

— Алайса авыр туфрагың җиңел булсын — дигән Зөлфәт



(«Литературная газета»).

...АР(О)ДӨЯ

Нияз АКМАЛ

Тик мин генә

Шул ук яз бу,
шул да түгел,
ничектер бераз үги...

Шул ук күз бу,
шул да түгел,
Нигәдер күе күгә...

Шул ук син бу,
тик мин генә,
тик күңел
шул ук түгел ..

(Акъегет, «Тонге сулар»)

Шул ук баш бу,
...л да түгел,
...чтер бераз гүли ..

Шул сыра бу,
шул да түгел,
нигәдер куе күбеге ..

Шул ук мин бу,
Мин дә түгел,
...күңел .. нәрсә күңел?!
Ә баш бит һаман гүли!

Язучы баласы

Бер танылган язучыдан сорыйлар икән

— Балаларың бик яхшы киенгән, ә үзең нишләп сәләмә киемдә йөрисең?

— Балаларым язучы баласы бит, ә мин үзем ярлы кеше углы, — дигән язучы

Депутат килен

Бер егет депутат кызга өйләнгән икән. Беркөнне аннан туган-кардәшләре

— Ну, депутат киленебез ничегрәк, — дип сорыйлар икән

— Болай начар түгел өебездә һәр кон сессия, атнага бер съезд үтеп тора, кайбер көннәрдә ишегалдында митинг ясыйбыз, йә пикет оештырабыз, каената белән каенананың отставкага чыгуларын таләп итеп, — ди егет.

Җиңгәңә ошаса...

Ике таныш очрашкач, берсе

— Габид Абдуллович! Ничек, эшләр барамы, машинаңа шофер алдыңмы әле? — дип сорый

Әнә яныма бер ыспай гына егет килеп йөри бүген килгәч үзен җиңгәгезгә күрсәтеп карыйм әле аңа ошаса иртәгә ук үз эшенә керешер ди гегесе

Мәзәкләрне Рәис САФАРОВ туплады

Мирасның асылы

«Базар! Базар!» — дип сөйләшәбез икән, димәк, — иртәме-соңмы, — сүзебез мирас мәсьәләсенә барып тоташачак. Азмыни хәзер йортны-фатирны, җирне-бакчаны, малны-акчаны мирас итеп алырга теләүчеләр. Тик менә мирас итеп калдырырга теләүчеләр күпмедер — анысын әйтүе кыен.

Хөер, безнең сүз исә рухи мирас турында бара.

Күптән түгел Татарстан Фәннәр академиясенең кульязмалар һәм текстология бүлегендә, Язучылар берлеге остаханәләре җитәкчеләре катнашында, нәкъ менә шундый мирас хакында зур сөйләшү булып узды. Дөресрәге, язучыларның һәм галимнәрнең кульязма китапларны, сирәк, борынгы язмаларны саклау, барлау, бүгенге көндәге кадерле истәлекләрне дә бергә туплау турында бу җитди мәсьәләне уртага салып сөйләшү өчен оештырылган фәнни-практик семинары иде бу. Әйдәгез, сүзне әлеге сөйләшүдә катнашучыларның үзләренә бирик.

Нил ЮЗИЕВ, галим һәм язучы, институтның кульязмалар һәм текстология бүлеге җитәкчесе:

— Мондый мәсьәлә буенча очрашу инде икенче тапкыр үткәрелә. Беренчесе моннан ун ел элек Язучылар берлегендә, язучыларның гомуми җыелышы рәвешендә үткән иде. Ун ел эчендә күп үзгәрешләр булып узды, әмма әдәби мирасыбызны туплау, саклау, өйрәнү мәсьәләләренең көн тәртибеннән төшкәне юк. Нәкъ без җыйналган вакытта Дәүләт советында мәдәни һәм тарихи ядкарьләрне саклау турында закон проектының тикшерелүе дә очраклы бер хәл түгелдер.

Безнең бүлек элек институтның фәнни архивы һәм текстология төркеме рәвешендә, әдәбият секторы эчендә генә яшәп килде. Ун ел элек ул аерым бүлек буларак оешты. Халыкның рухи мирасын туплау исә институт оештырылганнан алып көн тәртибенә куела. 1940 елда ук архивка Г.Тукай, М.Гафури, Ф.Әмирхан кебек әдипләрнең кульязмалары туплана башлый. Институт галимнәре 55 ел дәвамында җыйнаган һәм өйрәнгән кульязмалар хәзер мирасханәдә туплана бара.

Саннарга күчереп әйтсәк, хәзер мирасханәдә 100 меңгә якын саклау берәмлеген үз эченә алган 161 фонд бар. Шуларның 70тән артыгы — язучыларга, 7 фонд — халык иҗатына, 15 фонд сәнгатькә кагылышлы. Кульязма китапларга багышланган бер фондта гына да, мәсәлән, 5600 кульязма китап теркәлгән. Анда иске татар телендә, фарсы, гарәп, төрек телләрендә язылган уникаль, борынгы кульязмалар бар.

Без үзебезнең эшне фәнни нигездә — дөнья археографлары һәм текстологлары ирешкән казанышларга нигезләнеп оештырырга тырышабыз. Бүлекнең кульязмалар төркеме (җитәкчесе Марсель Әхмәтҗанов) борынгы кульязма ядкарьләрне һәм мәдәният әһелләренең шәхси архивларын җыйнау, аларны фәнни эшкәртү белән шөгыльләнсә, текстологлар төркеме (җитәкчесе Зөфәр Рәмиев) мирасханәдә тупланган язма истәлекләрне һәм классик әдипләребезнең әсәрләре җыелмасын текстологик хәзерләү белән мәшгуль. Без бүлек эшенең әлеге тармагын да бик әһәмиятле вазифа дип саныйбыз. Моңа әле өченче бер тармак та — җыйналган ядкарьләрне саклау җаваплылыгы да өстәлә.

Хәлбуки, бүлектәге эш бүленешен кире кагып, бүлекнең эш нәтиҗәләренә шик белдергән тәнкыйтьчеләр дә юк түгел. «Мирас» фонды президенты Флүн Мусинның «Мирас» журналында (1994, №2) басылган әңгәмәсе бездә шундый фикер калдырды. Ул безнең бүлек хезмәткәрләрен турыдан-туры гыйльми вазифаларына керми торган эшләрдә файдалану белән мавыгуда, безне монополиягә омтылуда гаепләп, куркытып та, шомландырып та куя. Без һич тә мирас туплауда монополиягә омтылмыйбыз. Мирасыбызны туплау белән, билгеле булганча, архивлар, музейлар, китапханәләр шөгыльләнә. Алар безгә, без аларга ярдәм итешеп яшибез. Иң әһәмиятлесе — әлеге ядкарьләрнең дәүләт саклавына күчүе.

Н.ЮЗИЕВ.

М.ӘХМӘТҖАНОВ

Г.АХУНОВ.

И.ЮЗЕЕВ.

Язма истәлекләрне җыйнауга игътибарны киметсәк, мирасханәбездәге хәзинәне укучыларга җиткерү белән генә шөгыльләнүгә күчсәк, без дөрес юлдан читләшкән булыр идек. Без, язма мирасны җыйнау эшен һич тә сүлпәнләндерергә тиеш түгелбез, дип уйлыйбыз. Бу мәсьәләдә сезнең дә фикерне ишетәсе килә.

Соңгы биш елда гына да, мәсәлән, мирасханәгә 38 шәхси архив тупланган. Алар арасында шагыйрьләр Хәсән Туфан, Нури Арслан, композиторлар Сара Садыйкова, Җәүдәт Фәйзи, әдәбият галимнәре Гали Халит, Хатыйп Госман, драматург Риза Ишморат архивлары һ.б. архивлар бар.

Мирасыбызны югалту куркынычы һәр адымда сагалап тора. Иске язуларны саклап килгән картлар үлү белән, татар телен һәм искечә язуларны белмәгән буын ул байлыкларны зиратка күмә, суга агыза, утилгә озата. 13 ноябрь көнне Мәскәү телевидениесе шагыйрь Михаил Львовның шәхси архивын язучыларның Переделкинодагы дачаларындагы чүплек өеменнән табып алу турында хәбәр итте. Мондый хәлләр бездә очрамыймыни? Бездә дә бит әле Хәсән Туфанның хатларын, чүплектән табып, Язучылар оешмасына китереп тапшырганнар иде. Әле ярый, язучының иҗат мирасы комиссиясе, вакытында тырышлык күрсәтеп, без Хәсән Туфанның архивын тулы рәвештә мирасханәгә алуга ирештек...

... Моннан берничә ел элек бер агай безгә гаять кызыклы документ тапшырды. Анда Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән Афзал Шамов белән Сибгат Хәкимне профсоюз оешмасында тикшерү турында сүз бара. Шул чорның чирләрен ача торган гыйбрәтле беркетмә бу.

Ул беркетмәне агай Татарстан китап нәшриятының коридорында өелеп яткан кәгазьләр арасыннан тапкан икән.

Соңгы елларда без «Казан утлары» журналы редакциясенең архивын алдык. Әмма ул без көткәнгә караганда күпкә ярлы булып чыкты... Ул архивны кемнәрдер инде сайлап чыккан дигән тәэсир кала. Мондый фактлар бездә мираска кагылышлы чыганакларны саклау культурасының булмавы, бу өлкәдә тәртипнең урнаштырылмавы хакында сөйли.

Шәхси архивларның саклануына кагылышлы тагын бер мәсьәлә күңелне борчый. Соңгы елларда мирасыбызга игътибар артуның күңелле күренеше буларак, районнарда язучылар һәм атаклы композиторларыбызның музейларын оештыру эше җәелә башлады.

Риза Фәхретдин музее, Хәсән Туфан музее, Муса Җәлил музейлары... Күп алар. Шул музейлар әдипләрнең истәлекле ядкарьләрен туплау буенча зур эш алып баралар. Мәсәлән, Ш.Маннурның шәхси архивын мәдәният министрлыгы аның туган авылындагы музеена тапшырды.

Әмма мондый тенденцияне мин үзем дөрес дип санамыйм. Язучының шәхси архивы дәүләтнең махсус оештырылган, саклануы ышанычлы булган мирасханәсендә торырга тиеш. Ә музей — күчермәсен алсын...

Тагын да бер җитди мәсьәлә күңелгә тынычлык бирми. Ул — кульязмаларның гомерләрен озынайту мәсьәләсе. Кәгазьгә язылган язма — мәңгелек түгел. Ул вакытлар үтү белән юкка чыга. Хәзер цивилизацияле илләрдә кульязмаларны саклау буенча киң күләмдә, дәүләт дәрәҗәсендә оештырылган эш бара. Уникаль кульязмаларны химик юл белән ныгыталар, яисә аларның күчермәләрен төрле рәвештә эшлиләр. Бездә хәзергә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» генә шундый ысул белән Мәскәү лабораторияләрендә ныгытылды. Бездә дә төрле мирасханәләрдә, архивларда саклаучы кыйммәтле ядкарьләрне шул ысул белән ныгыта алган, республика күләмендә эш итүче махсус консервацияләү лабораториясе ачуны көн тәртибенә кую зарур. Югыйсә, җыелган уникаль ядкарьләр әкренләп сүнә бара бит, аларны киләчәк өчен коткару кирәк.

Ф.Мусин укучыларның мирасханәдәге хәзинәләр белән таныш булмавы, рухи байлыкның бикләнеп ятуы өчен борчыла. Мирасханәнең ишекләре һәркем өчен ачык. Безгә ел саен меңгә якын кеше килеп, ядкарьләрне өйрәнә. Чит илләрдән дә күп киләләр. Текстологлар төркеме, мирасханә чыганакларына таянып, 70—80 нче елларда нәшрият белән берлектә классикларыбызның 40 томын чыгарды. Хәзер дә әдәбият ядкарьләрен басмага әзерләү буенча эш бара. Әмма дөньялар үзгәреп китү сәбәпле, әзерләнгән күп томнарыбыз басылмый ята.

Мирасханәдәге ядкарьләрне без башка юллар белән дә укучыларга җиткерергә тырышабыз. Мәсәлән, бүлек хезмәткәрләре соңгы биш ел эчендә генә дә 29 җыентык һәм китап бастырганнар. Ел саен дип диярлек, мирасханә хәзинәләренә багышланган махсус җыентыклар чыгарабыз. Быел җиденчесен әзерләдек. Көндәлек матбугатта пропагандалау буенча да эш бара. Биш ел эчендә биш йөздән артык мәкалә басылган.

Шулай да мирасханәдә басылмый яткан хәзинәне киң катлам укучыга ничек җиткерергә? Без менә бүген шул хакта да сөйләшсәк икән. Язучыларның сүзе үтемле; бу мәсьәләләрне сез дә күтәрсәгез, дөресрәге, бергәләп күтәрсәк, алар тизрәк чишелер иде. Мирасханәгә махсус бина, кульязмаларны саклау өчен тиешле шартлары булган бина булдыру да, минемчә, дәүләт кайгыртуында булырга тиеш. Халкыбызның мирасханәдә тупланган тарихи хәтерен килер гасырларга югалтмыйча илтеп җиткерәсе иде...

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ, өлкән фәнни хезмәткәр, филология фәннәре кандидаты:

— Безнең кулларда Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗани, Фатих Кәрими, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Туфан,
Сара Садыйкова, Га...
кебек күренекле ш...
безнең архив фонд...
лана. Кайбер язучы...
үз кульязмаларын ү...
китереп тапшырдыл...
дыйлардан Нәби Д...
вад Тәрҗеманов, ...
Фәттах, Илдар Юзе...
Миңнуллин, Риза И...
Гомәр Бәширов, М...
Мәһдиев, Ибраһим С...
Диас Вәлиев һәм б...
ны күрсәтергә була.

Музыка белгече ...
Хәйруллина татар м...
на һәм башкару сәнга...
гылышлы бик бай ...
мирасханәгә тапш...
ның белән татар с...
бу тармагына карага...
бай чыганаклар баз...
дырылды. Хореограф ...
Айдаров архивы да ...
мирасханәне баетып ...
де.

Безнең иң зур ф...
быздан берсе — бор...
лъязма китаплар. Бу ...
циядә 5600 берәмле...
саклана. Алар арас...
борынгы кульязма к...

1204, 1220 елларга ка...
Шулай ук XIY—XIX—X...
рларга караган ядкар...
шактый. XIII гасырның...
че яртысында яшәгән ...
линең атаклы «Йосыф...
бы» кульязмалары ...
нәдә 40 берәмлектән ...
Урта гасыр татар шаг...
ре һәм әдипләренең ә...
саклана. Аерым колл...
— халкыбызның 300...
тык шәҗәрә кульяз...
документлар коллекц...
— XYII—XX гасырлар...
ган 1000нән артык д...
лар, хатлар, метрика...
ләре бар.

Халкыбызның ба...
авыз иҗаты матер...
һәм музыкаль фольк...
малары коллекци...
дистәләрчә мең тә...
бар. Бу бик бай хәз...
мең берәмлектән а...
хисаплана. Ул мате...
безгә бүләк рәвеш...
махсус археографик ...
цияләр ысулы белән ...
тып алу юлы белән д...
ды.

Тупланган матер...
эшкәртеп, аларга т...
малар язып, фәнни ә...
кә кертү юлында да ...
зметкәрләре төркем...
дакарь эш алып ба...
эшкәртеләсе чыган...
күп әле. Иң зур, авыр...
бездән берсе — XIII г...
рдан килгән гарәп, ф...
ләндәге кульязма ки...
икенче баскыч т...
эше. Беренче нәтиҗ...
кызыклы: тасвирла...
мәгән китаплар ...
XIII—XYI гасырларга ...

...гесез кулъязмалар килеп ...га.

...Матбугат, телевидение, му... күргәзмәләре, конферен... ...ләр, фәнни җыентыклар ...а да кулъязмаларны дә... ...чыгарырга тырышабыз. ...зенең мәкаләләр «Казан ут...ры», «Идел», «Ялкын», «Та...рстан» журналларында, ...атаным Татарстан», «Тата...тан яшьләре», «Мәдәни җо...а» гәзитләрендә һ.б. басма...рда дөнья күрде.

...Быел гына да бездә Аме...кадан, Германиядән, Япо...ядән, Төркиядән, гарәп ил...ядән, Төркиядән... ...реннән килгән галимнәр бу...п китте. Әле күптән түгел ...ә Татарстан Дәүләт Сове... рәисе В.Лихачев, Төркиягә ...ганда, мирасханәбездә ...ңгы төрки һәм татар әдә...ның кыйммәтле ядкаре ...лган «Угызнамә» дастаны...ң уникаль кулъязмасыннан ...ынган күчермәне Төркия ...күмәтенә бүләккә алып ба...ы.

...Халкыбызның теләктәшле...дә мәдәни кыйммәтләрнең ...лануына ярдәм итә. Мәсә...н, «Идел» журналы редак...ясе хезмәткәрләре хәбәре ...енча, без быел Ленин ура-

кеч. Шуны антология итеп төзеп бирү, аларның биографияләрен дә булдыру — бу бик тә зур эш бит. Шул китап чыкмый ятсын инде, әй?! Архивта эшләүчеләргә, борынгы язмаларга табынучыларга бүләк бирелергә тиештер. Юкса, без «өзергә-бөзер»не чыгаручыларга бүләк бирергә күнектек. Бүләк төп эшне эшләүчеләргә бирелергә тиеш, минемчә.

Архивка мин дә үз кулъязмаларымны өзерләп тапшырачакмын. Миндә Әлмәт язучылар оешмасының тезелү документлары да, Татарстан Язучылар берлегенең үзем эшләгән дәвердәге (1974-1984 — ун ел!) язма-документлары да, укучылардан килгән 10 меңнән артык хат, язучыларның бер мең чамасы хаты бар.

Ун ел эчендә без татар язучыларының Мәскәүдә 350 китабын чыгардык. Мин Мәскәү нәшриятларына ул китапларны чыгаруны үтенеп бик күп хат яздым. Кыскасы, институт архивына тапшырасы документлар да, язмалар да җите-

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА, шагыйрә:

— Бездә архивларны саклау культурасы, саклау өчен өзерләү культурасы юк. Язучыларның күпчелеге бу эшне белми Белгән суратта дә, архив өстендә эшләү, аны саклау өчен безнең язучыларның тормыш шартлары да юк. Кысан фатирларда яшәп, архивын кайгыртып торырга күп язучыларның мөмкинлекләре дә чамалы.

Мин, озак еллар китап нәшриятында, Язучылар берлеге аппаратында, Тукай клубында эшләгән кеше буларак, әдәби архивларның нинди хәлләрдә икәнлеген беләм. Китап нәшриятында элегрәк елларда архив белән эшләүче махсус кеше бар иде. Ул штат кыскартылды Соңгы елларда архив белән эшләүгә игътибар кимеде. Хәзер архив саклау өчен бирелгән бүлмәне дә кайсыдыр оешма алган дип ишеттем. Язучылар берлеге архивы да, бер бинадан икенче бинага күчү сәбәпле, тиешенчә эшкәртелеп, тиешенчә саклауга тапшырылмаган.

Архив белән эшләү өчен

...күпме тора?

Г.ЗӘЙНАШЕВА.

Ш.ГАЛИЕВ.

З.РӘМИЕВ.

...гы күрше йорттан гына ...әдәбият классигыбыз Фәтхи ...рнаш архивының бер кисә...н таптык.

...Материалларны консерва...ияләү — иң әһәмиятле эш...ләрдән берсе. Әгәр консерва...я эшләре алып барылмаса, ...кындагы ун елларда йөзләр... борынгы кулъязмалары...ызга юкка чыгу куркынычы ...ый.

...Һәр халыкның культура...н аның үз тарихына һәм ...әдәниятенә мөнәсәбәте бил...ли, дип юкка гына әйтмәгән...р. Икенчедән, мирасханәдә ...ләүчеләр өчен алмаш хәзе...ү мәсьәләсе дә бик мөһим. ...әр халыкның фәнгә, мәдә...ияткә булган ихтыяҗына су...р тиешләр генә җибәреләә ...рса, бу халыкның беркай...н да икътисадый үсеш пер...ективасы булмаячак.

Гариф АХУНОВ, язучы:

— Г.Ибраһимов исемендә... Тел, әдәбият һәм тарих ин...титутының кулъязмалар һәм ...кстология бүлегендә, гади...әк итеп әйткәндә, халкыбыз...ың әдәби һәм мәдәни мира...н саклау бүлегендә күптән ...ласым килеп йөри иде. Го...р уза торды, вакыт һаман ...мәде. Ниһаять, менә кил... Язучылар берлегенең ...анә җитәкчеләре Шәү...т Галиев, Илдар Юзеев һәм ...н, бу очрашу бик файдалы, ...гъкәле дип уйлыйбыз. Би...рдә әйтелде — институт тө...гән бер дистәгә якын китап ...шриятта басылмый ята, ди...рде. Тукай заманында 150 ...агыйрь булу — ул бит искит-

рлек. Ул эшне мин тиз арада эшләрмен, Ходай кушса...

Илдар ЮЗЕЕВ, шагыйрь һәм драматург:

— Язучының язган, басылган иҗаты — авторның үзенеке генә түгел, ул инде халык мирасына әверелә. Борынгы чорларда ул әсәрләр, кулдан-кулга күчерелеп, безнең заманга, безнең көннәргә килеп җиткән. Ә күпмеләре черәп, янып-яндырылып, юк ителеп, тарих хәрабәләрендә югалган. Менә хәзер язучының иҗатын саклау, киләчәк буынга исән-сау тапшыру өчен уңайрак шартлар бар: Татарстан Фәннәр академиясендә кулъязмалар һәм текстология бүлеге эшли. Бу бүлекнең кадерен белеп, язучыларыбыз үзләре исән чакта ук үз кулъязмаларын китереп тапшырсалар, мирасны саклауда да эш җиңеләер иде. Әмма безнең күп кенә каләмдәшләребез үз архивларына үзләре үк гамьсез карыйлар. Мин берничә язучыны мисал итеп китерә алам: алар үз әсәрләренең вариантларын юк итә баралар, истәлекле-тарихи фоторәсемнәрне дә сакламыйлар. Мираска карата гамьсезлек бездә гадәти хәлгә әйләнгән инде, ремонт-фәлән ясалганда редакцияләрдән чыгарып ташланган кулъязмаларның юк ителүен үзебез дә күзәтеп торабыз. Кыскасы, бездә мирасны саклауның дәүләт принцибы эшләнмәгән.

Тәкъдимем бар: бүгенге мөһим сөйләшүдә әйтелгәннәрне Татарстан Дәүләт советы комиссиясенә тапшырырга кирәк.

нәшриятта да, берлектә дә махсус кеше булсын иде. Бу эш елдан-елга яхшыра барасы урынга елдан-елга начарлана бара. Чөнки игътибар җитми. Китап нәшриятында кайбер яшь редакторлар, корректорлар төргәк-төргәк итеп бәйләп куйган архив материаллары әле дә күз алдымда: кайбер папкаларның тышына авторның фамилиясе язылган, папка эчендә икенче авторның кулъязмасы... Яшьләр игътибарлырак булсын иде.

Бүгенге очрашу бик эшлекле булды. Биредә эшләүче иптәшләр — тарихи кулъязмаларны табу, саклау эшендәге фидакарьләребез — милләт өчен зур эш башкаралар. Мин моны күреп куандым.

Шәүкәт ГАЛИЕВ, шагыйрь:

— Өч ел рәттән, Нил Юзиев җитәкчелегендә, Пермь, Курган, Чиләбе өлкәләрендә фольклор экспедициясендә булган идек. Борынгы кулъязмалар хәлен яхшы беләм. Җыю, саклауда еллар буе фидакарь эш башкарган атаклы галимнәребез, эшчәннәребез бар, рәхмәт аларга.

Кызганыч, әмма әле дә, фаҗигале еллардагыдай, тарихи әһәмияте булган язмалар утта яна, чүплеккә ташлана. Бусын инде гамьсезлек, җавапсызлык, битарафлык дигән «эчке дошманнар»ыбыз башкара. Чаң сугарга вакыт, җәмәгатьчелек фикерен туплыйк. «Мәдәни җомга»да шул хакта фикер алышу башларга

иде.

Әдәби мирасны, минемчә, һәр автор үзе исән чакта ук кайгыртырга тиеш Әхмәт Фәйзи архивын сеңлесе Зәйнәп апа пөхтәләп, машинкада күчереп куйган иде Шуңа күрә томнарын чыгару тиз арада эшкә дә ашты Архив гомереңбуе даими игътибар, тырышлык, вакыт сорый. Үзең өчен үзең иренсәң, синең өчен кем эшләр? Моның тәртибенә, культурасына өйрәтү дә кирәк.

Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»дәй, Хәсән Туфанның да папирос кәгазенә йөзәр юллар шигырь сыйдырган уникаль язмалары бар. Аларны да халыкка күрсәтергә иде Шагыйрь тентүләрдән, сөргеннәрдән, ипи йомшагына яшереп, аларны саклап алып кайта алган Киләчәккә, укучыларга җиткерү — безнең бурыч. 2000 елда классик шагыйребезнең тууына 100 ел булыр. Шул вакытта 5 томын өзерләп чыгарырга иде. Бу мәсьәләне дәүләт дәрәҗәсендә бүгеннән үк куйсак кына, хәл итеп булыр.

Зәфәр РӘМИЕВ, текстология төркеме җитәкчесе:

— Язучыларыбызның шәхси архивлары текстологик эш башкару ягыннан да зур әһәмияткә ия икәнлеген, шәт, беркем дә кире какмастыр. Әсәрләрен, күптомлы басмаларын матбугатка әзерләгәндә, әгәр инде без тулылыкка, текстларның төгәл, автор ихтыярын бозмыйча бирелешенә омтылабыз икән, әдипләрнең кулъязмаларына, автографларына мөрәҗәгать итәргә бурычлыбыз. Соңгы егерме елда безнең текстология төркеме (ул 1977 елда оештырылды) әзерләп чыгарган Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, М.Гафури, Һ.Такташларның күптомлы басмаларына кертелгән күп кенә текстлар Г.Ибраһимов исемендәге институт мирасханәсендә, Татарстан дәүләт музеенда, шәхси архивларда тупланган материалларга нигезләнеп эшкәртелделәр дә.

Бүгенге көндә язучыларыбызның шәхси архивлары безнең институт мирасханәсендә, Татарстан дәүләт музеенда, Казан милли мәдәният үзәгендә һәм башка кайбер урыннарда саклана.

Бу исә аларны фәнни максатларда файдалануда шактый кыенлыклар тудыра. Татар язучыларының шәхси архивлары белешмәсе һаман юк. Ә ул бик кирәк нәрсә. Урыс язучылары турында андый белешмә 1962 елда ук чыгарылган иде.

Күптән түгел мин аңа мөрәҗәгать итеп, Сәгыйть Сүнчәләй белән 16 ел дәвамында хат алышкан урыс язучысы И.Гриневскаяның шәхси фонды кайларда сакланганын белдем һәм Русия дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивыннан С.Сүнчәләйнең 20 хатын эзләп таптым.

Мин язучыларыбыз архивларын Казаннан читкә җибәрмәскә кирәк дип саныйм. Дөрес, архив материаллары, язучының автографлары — сакланыр өчен, музейларга килүчегә күрсәтер өчен җыела. Әмма шул ук вакытта алар тикшеренүчеләр, галимнәр игътибарыннан да читтә калмаска тиешле бит. Казаннан читтә булу теге яки бу архив материалларын фәнни максатларда өйрәнүгә зур киртә булып тора.

Тиздән Габдулла Тукайның, Фатих Әмирханның 110 еллык юбилейлары билгеләп үтеләчәк. Без, әдәбиятчы-текстологлар, бу олы вакыйгаларны ничек каршыларга җыенабыз соң? Бер яхшы эш эшләдек дип саныйм мин: ул — Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасын төзү Аны бастырып чыгаруны, ниһаять, Татарстан китап нәшрияты үзенең планына кертә алды Ул хәзер редакцияләнә, Тукай юбилеена чыгып җитәр дип өметләнәбез XX гасыр башында иҗат иткән 85 татар шагыйренең иң яхшы лирик һәм эпик әсәрләрен туплаган ике антология менә биш ел инде кулъязма хәлендә ята бирә. Шулай ук моннан биш еллар элек безнең институт галимнәре тарафыннан төзелгән, фактик мәгълүматларга гаять бай «Егерменче гасыр башы татар әдипләре һәм мәгърифәтчеләре» исемле биобиблиографик белешмә дә хәрәкәтсез ята

Тагын бер мәсьәлә. Дөресрәге, үтенеч. Бүгенге сөйләшүдә күренекле әдипләребез, Язучылар берлегенең остаханәләре җитәкчеләре катнаша. Сүзем сезгә, хөрмәтле язучылар. Архивларыгызга җитдирәк карасагыз икән.Кулъязмаларыгызда авторлык һәрчак ачык чагылган булсын иде, язылу вакытлары да күрсәтелсен иде. Биредә, бер караганда, шактый кечкенә нәрсәне искәртүемнең бер сәбәбе бар. 80 нче елларда мин һәм Фатыйма Ибраһимова М.Гафуриның дүрт томлы әсәрләре җыелмасын төзү белән мәшгуль булдык. Әдипнең безнең институт архивында тупланган кулъязмалары арасында язылу вакытлары күрсәтелмәгән шигырьләр, парчалар, чәчмә фрагментлар шактый булып чыкты. Кайчак язган әдип аларны? Октябрьгә кадәрге чордамы, әллә соңракмы? Аларны томнарда кайда урнаштырырга, ничек дип аңлатма бирергә? Әйтәсе килгәнем: шул текстология фәнендә хронология бик мөһим мәсьәлә. Ул дөрес һәм төгәл хәл ителгәндә генә, теге яки бу әдипнең иҗаты нинди юнәлештә үскәнлеген, иҗади фикерләве ни рәвешле үзгәргәнлеген ачыграк күрсәтергә була.

Нил ЮЗИЕВ.

— Сөйләшүдән күренгәнчә, күтәрелгән мәсьәләләр язучы мәнфәгате, аның архивын саклау белән генә чикләнми. Ул халыкның рухи мирасын туплау, аны саклау мәсьәләләренә, халык язмышына барып тоташа икән. Бүген мирасны саклау традицияләрен баету, язма мирасны саклау культурасын күтәрү турында да җитди сүз булды. Бу мәсьәләләр, әлбәттә, шулай ук язучылар даирәсе белән генә чикләнми. Ул дәүләт органнарына да кагыла. Халкыбызның бөтен катламнарына карый торган мәсьәлә ул. Аерым шәхесләр, аерым оешмалар гына түгел, бөтен халык бу мәсьәләдә бердәм булып күтәрелсә, үзенең рухи мирасына изге бер әйбер итеп караса гына, хәзинәләребез киләчәккә ышанычлы барып җитәчәк. Шуңа күрә биредә башланган сүз матбугат органнарында да туктаусыз дәвам итсен иде. Дәүләт органнары да бу турыда җитдирәк уйланып, төйнәлеп килгән төеннәрне тизрәк чишә торган карарлар кабул итәргә тиешләрдер.

Сәхифәне **Рәмис АЙМӘТ** әзерләде.

РЕДАКЦИЯДӘН. Бу эшлекле мәҗлестә сөйләнгән-әйтелгәннәрне гәзитебез битләренә урнаштырганда без, үз укучыларыбызга төрле аһ-зар ишеттерүне түгел, ә бәлки рухи мирасыбыз хакында бергәләшеп уйлашуны максат итеп куйдык. Әйдәгез, бергәләшеп уйлашыйк!

Мәдәни җомга

Язучы мөнбәре

Барлас КАМАЛОВ

Әхлак әлифбасы да «а»дан башлана

Габигатьтә фасыл чылбырының алышыну чоры. 1995 елның көзе тарихка китте, үз вахтасын Кыш бабайга тапшырды. Ап-актан киенгән Суык карт — аяусыз ревизор. Ул имин якларыбызны гадәтенчә саран гына хуплар да, авыл хуҗалыгындагы кимчелекләрне дә, промышленностьта, транспортта, төзелештәге җитешсезлекләрне керфектән керфек аерылганчы абайлап алыр һәм каты камчылар, сакалларын учлап туган ваемсызларны катгый имтиханга тартыр.

Республикабыз, тулаем алганда, кышны тыныч каршылый. Русия дигән корабльне паралич тоткан бер заманда Татарстан Республикасы палубасында хәл чагыштырмача тотрыклырак. Моны безне өнәп бетермәүчеләр дә икърар итә.

Базар икътисады дигән гуҗ авызына кереп, җан тәслим кылу ихтималыннан оркеп кал-



тыранган чорда, дикъкатебез барыннан да элек ризык хакындагы бик табигый уй-фикерләргә юнәлә.

Ризык — гомер тоткасы, яшәү чыганагы, бәхетле көн итүнең нигез ташы.

Әлеге җәһәттән дәхи дә Азнакай районы игенчеләренең каһарманлыгы хакында ихластан соклану сүзләре әйтми мөмкин түгел. Нефтьле төбәкнең басу фидакарьләре быел дәүләткә 48 мең тонна ашлык саттылар. Шуның 35 мең тоннасы — җилемсеelement бодай.

Бу районның йөз аклыгын гәүдәләндерерлек бер шәхесне атыйк. Ул — «Авангард» акционерлык җәмгыяте механизаторы Рамил Таҗиев. Уңган игенче «Дон» комбайны белән 25361 центнер бөртек суктырды.

Азнакайлыларның бу триумфаль адымы һич кенә дә очраклы хәл түгел. 1994 елның 58 көн өзлексез яңгыр яуган елак җәендә дә алар дәүләт амбарына 38 мең тонна ашлык саттылар. Монысы — Арча, Буа, Сарман районнарыннан кала дүртенче нәтиҗә иде.

Быел Татарстан Республикасы буенча бөртекләрнең һәр гектарыннан уртача 18 центнер уңыш алынган икән, республикабыз игенчеләре күмәк төстәге каһарманлык күрсәттеләр дигән сүз. Бу җиңүнең быелгыдай яңгырсыз елда яулануы аеруча мөһим. Ә бит Русия авыл хуҗалыгы министрлыгының 80 миллион тонна бөртекле ашлык җыеп алырбыз, дигән фаразы акланмады.

Татарстаныбыз быел бәрәңгедән, шикәр чөгендереннән дә әйбәт кенә уңыш алды. Ашларыбыз тәмле, чәйләребез татлы булыр дип ышаныйк. Кышка шундый өмет белән керәбез.

Промышленность эшчәнлегендәге хәлләрне ал да гөл диярлек түгел. Тулы көченә эшләгән предприятиеләр саны да зур түгел икән. Аяныч хәлгә аек карарга кирәк. Шуның белән бергә, кыргый икътисад шартларында да сыртларын сындыртмаган производство берләшмәләре бар. Шуларның берсе — «Теплоконтроль» берләшмәсе. Биредә җәйне утлы гамьсез, тирән зарсыз кичерделәр дияргә мөмкин. Монда көз башына кадәр хезмәт хакын өч мәртәбә күтәрделәр, хәзер айлык уртача өҗер 450 мең сум. Шушы күренеш бу предприятие җитәкчелегенең, белгечләр командасының катлаулы хәлләрне ерып чыгуда зирәклек, тапкырлык, тәвәккәллек күрсәтүләренең нәтиҗәсе. Предприятие товар җитештерү темпын айдан айга арттыра бара. Аларның продукциясен сатып алучылар исә чиратка тезелгән.

Менә тагын бер күркәм мисал. Зәй автоагрегат заводы. Анда да хезмәт хакы түләү өчен акчага зур кытлык. Мәгәр кискен хәлдән чыгу юлын тапканнар. Һәммә ризык, конкүреш әйберләре, җиһаз компьютерлар ярдәмендә эшләнгән шәхси исәпләрдәге хезмәт хакына сатыла. Ә кибетләр барлык товарны бартер юлы белән юнәтә.

Кыскартылуга эләккән эшчеләрне завод җитәкчелеге оештырган яңа производстволарга (хуҗалыкның яшел цехы, сәүдә цехы һ.б.) күчерәләр. Пенсионерларга игътибар зур.

Язын, көзен заводны аңлы рәвештә туктатып тору булды. Ул басулардагы һәм шәхси хуҗалыклардагы эшләрне җиренә җиткереп башкаруга багышланды.

Бу яңалыкларның башында урыс милләтеннән булган, әмма татар халкын чын-чынлап үз итүче, уңган оештыручы завод директоры Вадим Мишин, Зәй шәһәре һәм районының хакимият башлыгы Рәшит Сәет улы Мөхәммәдиев тора. Аларга халыкның рәхмәте таудан зур.

Һәркайда эш шул кимәлдә барсын иде дә соң! Юк шул. КамАЗ тикле гигантта да хәлләр күзгә күренеп четерекләнәнде. Шулай да декабрь башында манзара уңай якка үзгәрер, забастовка булмый калыр дигән өмет бар.

Туар таңнар, килер көннәрдә безне ниләр көтә? Әлеге сорауга республикабызның элекке Премьер-министры, Татарстан Республикасы халык депутаты Мөхәммәт Сабиров «Шәһри Казан» гәзитенә биргән интервьюсында болай җавап бирә:

«Хәзер нәрсә уйландыра? Беренчедән, декабрь сайлаулары нәрсә күрсәтер? Аннан соң, Русиянең Президенты кем булыр? Болар да мөһим. Русия белән бер икътисади мохиттә яшибез бит.

Татарстан өчен Русиядән бөтенләй читләшергә вакыт җитмәде әле. Бәлки, кайчан да булса андый көн килер. Ә бүгенгә Шартнамә, килешүләр юлы белән эш итәргә туры килә».

Декабрь сайлаулары... Русия Федерациясенең Дәүләт Думасына депутатлар сайлау. Кемнәрдер әлеге уңайдан җиңнәрен югары сызганган, кайберәүләр бөтенләй битараф, бүтән бер иш кешеләр бу сайлауларга аяк терәп каршы. Кем хаклы?

Татарстандагы 5 сайлау округы буенча 30 депутат теркәлгән. Шулардан сайлана алганнары кайсы татар халкының, Татарстан Республикасының хәленә керүче булыр?

Депутатлыкка кандидатлар арасында инде бер тапкыр Русия Федерациясенең Дәүләт Думасына депутат булып сайланган кешеләр дә бар. Әйтик, Әлмәт шәһәреннән Геннадий Егоров, Мәскәүдә гомер итүче Олег Морозов, Чаллыдан Владимир Алтухов, Чистай каласыннан Габделвахит Баһаутдинов, Казаннан Валентин Михайлов. Шулай ук Русия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасы депутатының ярдәмчесе булган Дмитрий Фомин Чаллыдагы 24 нче сайлау округыннан кандидат итеп күрсәтелгән.

